


# "Баш иябез Бөек елларга"

# 1941-1945

## Бөек Ватан сугышы чоры балалары турында Хәтер альбомы

## Югары Шытсу, Түбән Шытсу, Елыш авыллары буенча

***Сугыш чоры балалары***

***Офыкларга тулды кара төтен,***
***Төсен алды төтен далаларның.***
***Елга булып яше җиргә сеңде***
***Сугыш чорындагы балаларның.***
***Ил хәсрәте ирләр иңсәсендә,***
***Ат чыдамый торган авыр хезмәт.***
***Алтмыш тулмый җиргә иңә ирләр,***
***Илгә рәнҗеп, күрми кадер-хөрмәт.***
***Хәтер төпкеленнән ачы язмыш,***
***Сөрән сала авыл, калаларга.***
***Уйчан йөзләр, әле дә моңсу күзләр***
***Сугыш чорындагы балаларда.***

***(Р.Баттал)***

# Абдуллин Хәлиулла Абдулла улы



Абдуллин Хәлиулла Абдулла улы Югары Шытсу авылында 1937 нче елның 29 нчы сентябрендә крестьян гаиләсендә туа. Сугыш башланганда аңа 4 яшь була. Сугышның беренче көненнән үк Хәлиулла абыйның әтисе Сибгать абый сугышка китә.

Малайлар Саба тавында шуганда, көнчыгыш ягыннан көнбатышка таба төркем-төркем самолетлар оча торган булган. Шул вакытта малайлар, җиргә ятып: “Әтине кайтарыгыз,” – дип кычкырганнар. 6 яшьтә 1 нче сыйныфка укырга керә Хәлиулла абый. Түбән Шытсу мәктәбендә 7 нче сыйныфны, Икшермә мәктәбендә 8 нче сыйныфны тәмамлый. 15 яшеннән соң хуҗалыкта эшкә йөкләнә башлый. Ат белән тирес түгә, көтү көтә, аннары фермада атлы эштә эшли. 1956-1959 нчы елларда Совет армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, “Беренче май” колхозында эшли башлый Хәлиулла абый. 1962 нче елда Авыл хуҗалыгы механизаторлары әзерләүче Янил училищесын гел “5”легә генә тәмамлый. 17 ел колхозда тракторист булып эшләгән.

“Беренче тракторым МТ-32 иде”,- дип искә ала 17 ел колхозда тракторист булып эшләгән Хәлиулла абый.

1980 нче елдан ул умартачылык эше белән шөгыльләнә. Стажы - 22 ел. Бүгенге көндә Хәлиулла абый пенсиядә. Апасы белән бергә Югары Шытсу авылында яши.

“Һәр биш ел саен җиңүчегә медаль бирелә. **Медальләр**, **мактау кәгазьләре**, исемле сәгатьләрем бар,”– дип сөйли Хәлиулла абый.

# Амангулова (Миннеханова) Фәймә Миннехан кызы



Амангулова Фәймә Миннехан кызы 1938 нче елның 2 нче маенда Түбән Шытсу авылында туа. 7 класс белем ала. Сугыш башлангач, Фәймә апаның әтисен сугышка алалар. Ул сугыштан исән-сау әйләнеп кайта, озак еллар авылда мулла булып тора.

13 яшендә, 7 нче классны бетергәч, дуңгызлар карарга дип фермага эшкә алып менеп китәләр Фәймә апаны. Аннары соң бозаулар караудa, соңрак сыер савучы булып эшли. Ул бар тырышлыгын биреп эшли. 1978 елда **“Хезмәт Кызыл Байрагы” ордены** белән бүләкләнә, **“Ветеран труда” медале** бирелә. 1975 нче елда Авыл советы депутаты булып та сайлана.

1993 нче елда пенсиягә чыга Фәймә апа. Аннары 2003 нче елга кадәр тагын 10 ел амбарда, колхозда төрле эшкә йөри.

Бүгенге көндә бердәнбер кызы Наилә гаиләсендә яши.

# Ахсанова (Шафигуллина) Руза Рәшит кызы



Ахсанова Руза Рәшит кызы 1935 нче елның 6 нчы апрелендә Югары Шытсу авылында туа. Җиде класс белем ала. Әтисе, Шафигуллин Рәшит, 1938 нче елда үлә.

Сугыш башланганда Руза апага 6 яшь була. Бу дәһшәтле елларның ачы кайтавазы бүгенге көнгә кадәр саклана аның йөрәк түрендә.

“Тормышлар бик авыр булды. Ашарга ризык, өскә кияргә кием булмады. Мәктәптә яланаяк йөреп укыдык,” – дип искә ала Руза апа.

Ул колхозда төрле эшләрдә эшли. 12-13 яшьтән башлап 10 ел буе урман кисәргә йөри. Җәй көне печән чабарга, бәрәңге алырга йөртәләр. Озак еллар дуңгызлар карый. Районнан һәм колхоздан бирелгән **дипломнары**, **Рәхмәт хатлары** бик күп.

Бүгенге көндә Руза апа килене белән Югары Шытсу авылында яши.

“Киләчәк буынга без күргәнне күрергә язмасын,” – дип чын күңеленнән тели ул.

# Әхтәмҗанова (Шәйхелисламова) Гөлфәридә Шәйхелислам кызы



Әхмәтҗанова Гөлфәридә Шәйхелислам кызы 1937 нче елның 26 нчы мартында Югары Шытсу авылында туа. Әтисе - Шәйхелислам, әнисе Бибизәкия исемле була. Гөлфәридә апа җиде класс белем ала. Укып бетергәч , Югары Шытсу фермасында эшли. 1963 нче елда Түбән Шытсу егете Шамил абыйга кияүгә чыга. Ул эшен Түбән Шытсу фермасында дәвам итә. Тормыш иптәше Шамил абый белән бергә 3 бала тәрбияләп үстерәләр.

Бүгенге көндә Гөлфәридә апа Түбән Шытсу авылында гомер итә.

# Әхтәмҗанов Шамил Әхтәмҗан улы



Әхтәмҗанов Шамил Әхтәмҗан улы 1935 нче елның 15 нче декабрендә Түбән Шытсу авылында дөньяга килә. Әтисе – Фәләхетдинов Әхтәмҗан, әнисе - Тәхәветдинова Корбанбикә. Әтисе сугышка китә һәм 1946 нчы елда әйләнеп кайта. Фин сугышында да катнаша. Шамил абый җиде класс белем алганнан соң , колхозда тракторчы, электро-сварщик, токарь, завхоз булып эшли.

Хәзерге көндә дә Шамил абый умартачылык белән шөгыльләнә. Үз шөгылен балаларына, оныкларына өйрәтә.

# Баһманов Җәмил Баһман улы



Баһманов Җәмил Баһман улы 1937 нче елның 5 нче августында Югары Шытсу авылында туган. Әтисе сугышка киткәндә аңа 5 яшь була. 7 класс белем ала. “Ул чор балалары кебек, миңа да тормыш авырлыкларын олылар белән бергә күтәрергә туры килде. Сугыш беткән, безнекеләр җиңгән, дигән шатлыклы, әйтеп-аңлатып булмаслык сөенечле хәбәрне мин мәктәптә укыганда ишеттем,” - дип искә ала Җәмил абый.

Армиядә чакта поварлыкка укый Җәмил абый һәм диңгез флотында хезмәт иткәндә пешекче булып эшли. Армиядән кайткач, электрик булып эшкә урнаша. Шушы хезмәте 35 ел - пенсиягә кадәр дәвам итә.

1966 нчы елда Мәшүдә исемле кыз белән гаилә корып җибәрә Җәмил абый. 5 бала - 4 кыз һәм 1 малай үстерәләр. Хәзерге көндә ул лаеклы ялда.

“Илләребез генә тыныч булсын, яңадан сугыш афәтен татырга язмасын, дип тынычлык телим, булганына куанып яшим,” – ди Җәмил абый.

# Билалова Исмегөл Фархулла кызы



Билалова Исмегөл Фархулла кызы 1936 нчы елның 6 нчы ноябрендә Югары Шытсу авылында дөньяга килә. Заһидуллин Фархулла белән Бәдыйгельнең зарыгып көткән беренче баласы була ул.

"Сугыш елларының нужасы безнең бала чакны алды. 8 яшьтән басуда чуп утап эш башлап жибэрдем, аннан сложный молотилкада икмәк сугу, басуда эскерт кую, кирпеч сугу дисеңме һәм башка төрле эшләр башкардым,” – дип сөйли Исмегөл апа. Авыр еллар булганлыктан, 4 класс белем белән тукталып кала, алга таба белемен арттыра алмый. 12 яшьтән фермага дунгыз карарга эшкә керә ул. Аннары колхозда төрле эштә йөри, һәртөрле эшне намус белән башкара. Соңрак медпунктта җыештыручы хезмәтен үти һәм лаеклы ялга чыга.

Исмегөл апа Югары Шытсу авылы егете Зөфәр абый белән тормыш кора. Аның белән 4 бала – 2 малай, 2 кыз тәрбияләп үстерәләр.

Бүгенге көндә Исмегөл апа Югары Шытсу авылында гомер кичерә.

# Вәлиәхмәтова Рәхилә Галимҗан кызы

Вәлиәхмәтова Рәхилә Галимҗан кызы 1938 нче елның 4 нче гыйнварында Саба районы Мамалай авылында туа. Әтисе-Галимҗан, әнисе Маһисәрвәр исемле була. Әнисе 1943 нче елның гыйнвар аенда, алты баланы ятим калдырып, каты авырудан дөнья куя. Бу вакытта Рәхилә апага нибары биш кенә яшь була.Әтисе Галимҗан 1942 нче елда сугышка китә. Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, 1946 нчы елның март аенда исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп була аңа.

Рәхилә апага 1945 нче елда 7 яшь була. Сугыш вакытында болынга көлтә өяргә, печән җыярга, басуга чүп тырмаларга йөргәннәрен тирән көрсенү белән искә алып сөйли ул.

Рәхилә апа башлангыч белемне Мамалай мәктәбендә ала. Җиденче классны Баландыш мәктәбендә тәмамлый. Укуын бетергәч, ике ел Мамалай май заводында эшли. Аннан фермага сыер саварга керә. Ике ел эшләгәч, 1957 нче елда Түбән Шытсуга Фоат абыйга тормышка чыга.Тормыш иптәше белән ике малай, бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Башта төрле эштә эшли Рәхилә апа, ә 1960 нчы елда Түбән Шытсу фермасына сыер саварга керә һәм утыз ел буе колхозда сыерлардан мул сөт алу буенча I урында бара. Түбән Шытсу фермасында 60 яшькә кадәр эшләвен дәвам итә ул. Рәхилә апа эшләү дәверендә бик күп грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнә. 1993 нче елда **“Хезмәт ветераны”** медаленә лаек була, **ВДНХдан бронза медаль** белән бүләкләнә.

Бүгенге көндә Рәхилә Галимҗан кызы Түбән Шытсу авылында гомер итә, абыстай вазыйфасын башкара.

# Вәлиәхмәтова Шәмсенур Хөсәен кызы



Вәлиәхметова Шәмсенур Хөсәен кызы 1938 нче елның 15 нче ноябрендә Түбән Шытсу авылында туа. Гаиләдә 10 бала булалар. Шәмсенур апа җиде класс белем ала. Әтисе сугыш башлангач сугышка китә һәм исән-сау әйләнеп кайта. "Сугыш вакытында без алдагы көнгә өмет белән яшәдек. Безнең әниебез бик тырыш, көчле рухлы иде, аның ярдәме белән без исән калдык. Сугыш башлангач, тормыш бик авыр булды. Ашарга табуы авыр булды. Ашарга яраклы яшеллек белән тукланадык. Басуда кыр эшләрендә булыштык: җитен, борчак йолыктык, башак җыештык,"- дип искә ала Шәмсенур апа.

Укуын тәмамлагач, фермага сыер саварга керә ул һәм лаеклы ялга чыкканчы шунда эшли.

"Бәхетле булсыннар, беркайчан сугышлар булмасын. Без күргән авырлыкларны күрергә язмасын," – дип хәзерге буынга теләкләрен җиткерә Шәмсенур апа.

Бүгенге көндә Шәмсенур Хөсәен кызы Түбән Шытсу авылында гомер итә.

# Габбазова Зөлфия Хуҗа кызы



Габбазова Зөлфия Хуҗа кызы 1941 нче елның 15 нче гыйнварында Спас районы Юксыл авылында крестьян гаиләсендә туа. Сигез класс белем ала.

“Сугыш вакытында ашарга яраклы яшеллек белән тукландык. Басуда кыр эшләрендә булыштык: җитен, борчак йолыктык, башак җыештык. Фронтка дип май, йомырка, кипкән бәрәңге җибәрдек,” – дип сөйли Зөлфия апа.

Укуга сәләте шактый зур булса да, сугыш авырлыклары белемен арттырырга мөмкинлек бирми аңа. Баштарак сатучы, аннары газ операторы хезмәтләрен башкара ул.

Зөлфия апаның 4 баласы, 10 оныгы бар.

Бүгенге көндә тормыш иптәше Фаяз белән Түбән Шытсу авылында гомер кичерә.

“Бер генә теләгем бар: бүтән мондый сугышлар, ачлык, ялангачлык вакытлары кабатланмасын, Амин!” – дип теләк тели Зөлфия апа.

# Габдерәкыйпова (Галимуллина) Гәмбәрия Шәрип кызы





Габдерәкыйпова (Галимуллина) Гәмбәрия Шәрип кызы 1938 нче елның 25 нче октябрендә Түбән Шытсу авылында крестьян гаиләсендә туа. Сугыш башлангач, әтисе сугышка китә һәм хәбәрсез югала.

Сугыш башланганда Гәмбәрия апага 3 яшь була. Гаиләдә алар дүрт бала була. Тик сугыш авырлыклары , ашарга җитмәү, ниндидер чирләр аркасында ике сеңлесе бала вакытта үлә. Авырлыклар аркасында ул бары тик 3 сыйныф белем ала. Аннан инде хезмәт юлы башлана. Аның 48 ел эш стажы бар. Ул бозаулар да караган, мәктәптә җыештыручы да булып эшләгән, дуңгызчылык тармагында да хезмәт куйган, аннан 20 ел сыер сауган. Хезмәтенең нәтиҗәләре дә була: аның **Мактау грамоталары, “Победитель соцсоревнования”, “Ударник пятилетки” күкрәк билгеләре** бар. Уңышлы эшләре өчен **3 нче дәрәҗәдәге Дан ордены** белән бүләкләнә. Бүгенге көндә ул **Хезмәт ветераны**.

Гәмбәрия апа 1961 нче елда Түбән Шытсу авылы егете Габдерәкыйпов Габделәхәт белән тормыш корып җибәрәләр. Алар дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә ул тыныч, мул тормышка куанып, илләргә иминлек, тынычлык теләп яши.

# Габдерәкыйпов Габделәхәт Габдерәкыйп улы



Габдерәкыйпов Габделәхәт Габдерәкыйп улы 1934 нче елның 9 нчы октябрендә Түбән Шытсу авылында крестьян гаиләсендә туа. Сугыш башлангач, әтисе сугышка китә, ләкин әйләнеп кайтмый.

Сугыш башланганда Габделәхәт абыйга 7 яшь була. Гаиләдә алар 4 бала булалар. Бик авырлыклар белән үсәләр.

Сугышның башлануын өйдәгеләрдән ишеттем, диеп искә ала Габделәхәт абый. Бары тик 4 кенә класс белем ала. 3 елда 8 ай Совет армиясе сафларында Венгриядә хезмәт итә.

Армиядән кайткач, колхозга эшкә керә. Озак еллар бригадир булып эшли. Аның почет грамоталары бик күп. **“Ударник пятилетки” күкрәк билгесе** бар.

1961 нче елда Түбән Шытсу авылы кызы Гәмбәрия апа белән тормыш корып җибәрәләр. Алар өч кыз, бер ул үстерәләр. Бүгенге көндә кече уллары Мирхәт гаиләсендә тыныч картлык кичерәләр.

# Габдрахманова (Миннемөхәммәтова) Оркыя Миннемөхәммәт кызы

Габдрахманова (Миннемөхәммәтова) Оркыя Хаммат кызы 1935 нче елның 3 нче ноябрендә Миннемөхәммәт белән Мәрфуга гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Әтисе сугышка киткәндә Оркыя апага 6 яшьләр тирәсе була. Әниләре 5 бала белән торып кала. Барлык сугыш чоры балалары язмышы белән аваздаш Оркыя апаның язмышы. Авыр хезмәт, ачлы-туклы тормыш – боларның барысы аша үтәргә туры килә аңа. Оркыя апаның әтисе Миннемөхәммәт сугыштан яраланып кайта. Күрсәткән батырлыклары өчен бирелгән бик күп орден-медальләре 1956 нчы елда булган янгында юкка чыга. Миннемөхәммәт абый 1959 нчы елның 16 нчы апрелендә вафат була.

Оркыя апа 7 яшендә Югары Шытсу башлангыч мәктәбенә укырга керә. Анда 4 класс белем алгач, Түбән Шытсу авылындагы сигезьеллык мәктәптә 5 нче классны укый. Кызганычка каршы, алга таба белем алырга мөмкинлеге булмый Оркыя апаның.

Ул 16 яшьтән колхозга эшкә чыга. Баштарак сарыклар үрчетү фермасында эшли, аннары дуңгызчылык фермасына күчә һәм гомере буе биредә хезмәт куя. Оркыя апаның эш стажы 41 елны тәшкил итә. Лаеклы ялга чыккач та ул колхозда төрле эшкә йөри.

1972 нче елда Оркыя апа ике бала белән тол калган ир - Габдрахманов Рифкать абый белән тормыш кора. Берсеннән-берсе кечкенә ике малайны үз канаты астына сыйдыра ул. 1973 нче елда Оркыя апа белән Рифкать абыйның кызлары Дилә, 1977 нче елда уллары Раиф дөньяга килә.

Бүгенге көндә Оркыя апа Югары Шытсу авылында улы гаиләсе белән яши. Аның эшләгән дәвердә алган бүләкләре шактый:

**- Почетное звание “Лучшая свинарка района” – 1982 г., 1983 г.;**

**- “Победитель социалистического соревнования” – 1976 г., 1980 г.;**

**-Участник торжественного митинга, посвященного выполнению социалистических обязательств сдачи хледа государству (г.Казань) – 1982 г.**

**- Колхоз производствосындагы күпъеллык тырыш хезмәтләре өчен Почет грамотасы – 1972 г., 1980 г., 1985 г.;**

**- 1970 нче елның 25 нче февралендә Саба районы “1 Май” колхозының Почет китабына кертелә;**

**- 1983 нче елда район Мактау тактасына кертелә.**

**Габделвәлиева (Гумерова) Сания Ибраһим кызы**





Габделвәлиева (Гумерова) Сания Ибраһим кызы 1937 нче елның 20 нче октярендә Югары Шытсу авылында туа. Әтисе Ибрагим авылда бригадир, сөт җыючы булып эшли. Аны ашлык урлауда гаепләп, төрмәгә утырталар һәм шуннан соң сугышка алып китәләр. Әтисе сугышка киткәндә Сания апага нибары 4 яшь була.

Җиде класс белем ала ул. Дүртенче класска кадәр китапсыз, ярты карандаш һәм дәфтәр белән укый.

“Сугыш вакытларында ашарга хәтта кычыткан да тапмый идек. Әни табып алып кайткан кычытканнарны да урлап алып чыгып китәләр иде. Берьюлы әни эштә вакытта без өйдә үзебез генә ачтан шешенеп беткәнбез. Әни, кайткач, безне күреп елап җибәрде. Аннары безне арыш арасына утыртты да , арыш башы ашагыз дип, кире эшенә китте,” –дип искә ала Сания апа.

Сания апа сугыш беткәнне 1945 нче елда укытучыларыннан белеп кайта. Ләкин сугыш бетүгә үк тормыш җайга салынмый. 1964 нче елларга кадәр халык җәфа чигеп яши: ашарга, өс-башка кияргә бернәрсә булмый.

Сания апа 1958 нче елда Сәлимҗан абыйга кияүгә чыга. Алар бергә өч бала үстерәләр. Үзенең тормыш юлында ул күп урыннарда эшли: Мәскәүдә бригадада, колхоз басуында икмәк сугуда, 10 ел сөт җыюда.

Бүгенге көндә Сания апа Югары Шытсу авылында гомер итә.

# Габделганиева Шамсенур Габделгани кызы



Габделганиева Шамсенур Габделгани кызы 1944 нче елның 24 нче ноябрендә Югары Шытсу авылында Габделгани белән Фәрхинур гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килә. Сугыш башланганда 6 ай була Шамсенур апага. Аның әтисен сугышка алалар, ул, күзенә пуля ярчыгы тиеп, яраланып кайта.

Шамсенур апа 1952 нче елда беренче сыйныфка укырга керә. Укуын бетергәч тә фермада дуңгыз, соңыннан сарык карый. Эшләгән вакытта бик күп медальләр, дипломнар һәм **Татарстан Республикасы Президентының Мактау хаты** белән бүләклиләр Шамсенур апаны.

1977 нче елда Гарипов Фатихка кияүгә чыга ул. Тормыш иптәше белән бер кыз һәм бер ул үстерәләр. Кызганыч, бүгенге көндә Фатих абый инде безнең арабызда юк.

Шәмсенур апа Югары Шытсу авылында улы гаиләсендә гомер итә.

# Гайбадуллина Хәкимә Хисмәт кызы



Гайбадуллина Хәкимә Хисмәт кызы 1937 нче елның 9 нчы августында Җөри авылында гади эшчеләр гаиләсендә дөньяга килә. Ул җиде класс белем ала.

Сугыш башланган, дигән дәһшәтле сүзне почтальон кереп әйтә аларга.

“Сугыш чорында бала-чага гына булсак та олылар белән бергә көн озын башак җыя идек”,-дип хатирәләрен яңарта Хәкимә апа.

Сугыш вакытлары, балачаклары турында сораша башласаң, гел сүзен бүгенге көнгә шөкерана кылып, бүтән андый афәт ачыларны беркемгә дә татырга язмасын, Ходаем, дип тәмамлый Хәкимә әби. Димәк, ул вакыттагы авырлыклар, мәхшәрләр, ачлык газаплары ул чор балаларының үзәгенә үткән.

“Әтиемнең атка утырып киткәнен хәтерлим,” - ди Хәкимә әби.

Шул китүдән әтиләре бүтән кайтмый, сугыш кырында һәлак була.

Хәкимә апа озак еллар колхозда төрле эштә эшли.

Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында яши.

# Гайсина (Сәйфетдинова) Асия  Гыйльметдин  кызы



Гайсина Асия Гыйльметдин кызы 1936 нчы елның 14 нче сентябрендә Түбән Шытсу авылында туа. Гаиләдә дүртенче бала була. Асия апага 4 яшь булганда әтисе Гыйльметдин сугышка китә, аннан бер аяксыз булып кайта.

Авыр еллар булуга карамастан, җиде класс белем ала Асия апа. Аннан яшьтән үк колхозда төрле эшләрдә эшли.

Асия апа 1958 нче елда Түбән Шытсу авылы егете Шаһимулла абыйга кияүгә чыга. Аның белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр: 2 кыз, 1 малай. 1965 нче елда Пермь ягына эшкә китәләр. 1995 елда кире туган якларына әйләнеп кайталар.

Бүгенге көндә тормыш иптәше белән Түбән Шытсу авылында гомер итәләр.

## Галиәхмәтова (Мусина) Һәдия Габдулла кызы




Галиәхмәтова Һәдия Габдулла кызы 1934 нче елның 16 нчы октябрендә Югары Шытсу авылында Мусин Габдулла Муса улы белән Мусина Әминә Гәбҗәлил кызы гаиләсендә туа. Сугыш башланганда аңа 6 яшь була. Сугыш вакытында башлангыч белем ала. Зурларга ияреп басуга утауга йөри.

“Утаган чүп үләннәрен күтәреп алып кайтып, кышка киптерә идек. Ашау-эчүгә килгәндә, ул елларда бар кеше дә бер төрле, төп ризык - бәрәңге, ипи-икмәк телемләп кенә бүленә иде,” – дип искә ала Һәдия апа.

Балачагының бер кызыклы истәлеге итеп, беренче чын тупны күрүе, аның белән уйнавы турында сөйли. Ул тупны Мәскәү янына окоп казудан кайткан авылдашыбыз Хисамиева Минҗиһан апа алып кайткан була. Бөтен урам баласы шунда җыелып туплы уйнаганнар.

Сугыш бетәр алдыннан гына әтиләре бик нык яраланып госпитальдә ята, аннан өйләренә кайтарыла.

Әтисе сугыштан кайтканны ул бүгенгедәй хәтерли. Төнлә ишек шакыйлар, әнисе чыгып эндәшә:

- Кем бар анда? Габдулла, синме? - ди.

Барысы да сикерешеп торалар, ул, чыннан да, әтиләре була. Һәдия апа әтисенең күп яралы булуын һәм әнисенең ничек итеп әтисен каравын, шул тәнендәге кыйпылчыклар белән әтисенең бу дөньядан китүен авыр сулап искә ала.
Һәдия апа Югары Шытсу авылы егете Мөкътәсим абый белән гаилә кора. Алар 4 кыз тәрбияләп үстерәләр.

Бүгенге көндә Һәдия апа Югары Шытсу авылында гомер итә.

# Галимуллина (Гайнетдинова) Шәмсебаян Әхтәмҗан кызы



Галимуллина Шәмсебаян Әхтәмҗан кызы 1941 нче елның 28 нче гыйнварында Түбән Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Сугыш башланганда аңа 4 ай гына була. Әтисе белән әтисенең абыйсы сугышка китәләр.


Шәмсебаян апа 7 класс белем ала. Мәктәпне бетергәч, фермада сыер сава, бозаулар карый. 1969 нчы елда үз авыл егете Рифкать абыйга кияүгә чыга. Аның белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр.

Шәмсебаян апаның әтисе сугышта хәбәрсез югала. Аның кайда, ничек һәлак булганын да белмиләр. 2016 нчы елның декабрендә Санкт-Петербургтан хәбәр килә. Анда әтисе Гайнетдинов Әхмәтҗанның кабере табылганлыгы турында язылган була.

Шәмсебаян апаның кулында бик күп **Рәхмәт хатлары**, **Мактау кәгазьләре**. Ләкин иң кадерлесе - 1970 нче елда бирелгән **“За достигнутые успехи в развитии народного хозяйства СССР” ның көмеш медале**.

Бүгенге көндә Шәмсебаян апа Түбән Шытсу авылында гомер итә.

## Галимуллин Рифкать Хөснулла улы



Галимуллин Рифкать Хөснулла улы 1944 нче елның 27 нче февралендә Түбән Шытсу авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе Хөснулла сугышка китә, сугыш беткәч, туганнары янына исән-сау әйләнеп кайта.

Рифкать абый сугыш башланганда сабый бала була. Ул сугыш беткән чорларны да исенә төшерә алмый.

"И, ул чакларда авыл җирендәге бала-чаганың күплеге, – дип искә ала Рифкать абый. – Барыбыз да гади, эчкерсез, барыбызны да сугышның ачы җилләре җитәрлек газаплаган… Шулай да, дус-тату идек үзебез, бары – бергә, югы – уртак, дигәндәй… Җәйләребез болында җиләк җыеп, кузгалак, юа ашап үтсә, кышларын, аз гына җай чыгуга, тау шуарга йөри идек… Кырыклап-иллеләп бала, көн кичкә авышканчы әвәрә килеп чырылдаша идек шунда. Итекләребез, бишмәт итәкләребез бозланып катканчы, бит-кулларыбыз тәмам кызарып, күшегеп беткәнче тау шуабыз. Ачыгып, инде суык чын мәгънәсендә үзен сиздерә башлагач, өйләргә таралабыз".

Рифкать абый 7 класс белем ала. Укыган чорларда да колхозда төрле эшләрдә йөри.

1963-66 нчы елларда армия сафларында хезмәт итә.

1969 нчы елда Түбән Шытсу авылы кызы Шәмсебаянга өйләнә. Аның белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Гомер буе колхозда терлекчелектә эшли Рифкать абый.

Хәзерге көндә хатыны Шәмсебаян апа белән Түбән Шытсу авылында яшиләр.

# Гәләвиева (Сафина) Фәүзия Корбан кызы



Гәләвиева Фәүзия Корбан кызы 1934 нче елның 13 нче мартында Түбән Шытсу авылында дөньяга килә. Гаиләдә алар 6 бала үсәләр.

Сугыш башланганда Фәүзия апага җиде яшь була. Әтисен сугышка алгач, әниләре 4 бала белән кала.

“Ашарга юк. Басудан черек бәрәңге җыеп, кузгалак, какы, алабута җыеп әни безгә шуннан ризык әзерләп ашата иде,” – дип искә ала Фәүзия апа.

Мәктәптә укый башлагач, нинди эш кушсалар, шуны эшли Фәүзия апа: басудан көлтә ташый, башак җыя, урманнан ботак ташый.

“Иң истә калганы - әтинең сугыштан исән-сау кайтуы иде. Сугыш беткәч бик шатландык,” – ди Фәүзия апа.

Әмин исемле егеткә кияүгә чыгып, бер кыз, өч малай тәрбияләп үстерәләр алар. Озак еллар гаиләсе белән Пермь өлкәсендә яши Фәүзия апа. Гомере буе балалар бакчасында балалар карый ул.

Пенсиягә чыккач, туган авылларына әйләнеп кайталар һәм бүгенге көндә дә биредә бәхетле гомер кичерәләр.

# Гарипова Мәшүдә Кәнәфи кызы



Гарипова Мәшүдә Кәнәфи кызы 1945 нче елның 25 нче мартында Югары Шытсу авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе Кәнәфи абыйны беренче көннән үк сугышка алалар. Яралану сәбәпле, ул Җиңү көне җиткәнче үк туган авылына әйләнеп кайта.

Мәшүдә апа башлангыч белемне Югары Шытсу мәктәбендә, җидееллык белемне Түбән Шытсу мәктәбендә ала. Кичке мәктәпкә йөреп, 10 нчы классны тәмамлый.

Озак еллар фермада терлекчелектә эшли. Район һәм авыл җитәкчеләре Нурзия апаның эшләгән эшләрен югары бәялиләр. Нинди генә эшкә тотынса да, үз эшенең остасы була ул. Бер эштән дә куркып, югалып калмый. Мәшүдә апаның эш стажы 41 елны тәшкил итә.

“Балакайлар! Сугыш чоры балалары бик күп михнәтләр күргән. Хәзерге тормышның кадерен белегез, тырыш һәм әдәпле, сәламәт булыгыз,” – дип теләкләр тели Мәшүдә апа.

Бүгенге көндә ул Югары Шытсу авылында гомер итә.

# Гарипова (Аскарова)  Мөнирә  Габделхак кызы



Гарипова Мөнирә Габдулхак кызы 1933 нче елның 10 нчы гыйнварында Арча районы Кәче авылында дөньяга килә. Әтисе Габдулхак, әнисе Сәрвәр бик тырыш кешеләр булалар. Алар 5 кыз тәрбияләп үстерәләр. Сәламәтлеге начар булу, бер күзе күрмәү сәбәпле, аларның әтиләрен сугышка алмыйлар, ә корал ясау заводына эшкә җибәрәләр. Сугыш беткәнче, әтиләре шунда эшли. Сугыш беткәч, 2 елдан соң гына кире гаиләсе янына әйләнеп кайта. Ачлы-туклы эшләү эссез калмый, кайтып, бер ел гына яшәп, ашказаны рагыннан үлеп китә. Әниләре Сәрвәр 5 кызны берүзе тәрбияләп үстерә. Колхозда бригадир булып эшли, бик күп мактау грамоталары ала. Казанга депутат булып сайлана. Мәскәүгә берничә тапкыр съездга бара.

Мөнирә апа Кәчедә 8 еллык мәктәпне бетергәч, Арча педагогия көллиятенә укырга керә. Көллиятне тәмамлап, юллама белән Саба районы Түбән Шытсу авылына эшкә килә. 1951 нче елдан 1989 нчы елга кадәр Түбән Шытсу мәктәбендә укытучы булып эшли. 1953 нче елда Түбән Шытсу авылы егете Гарипов Хәкимҗанга кияүгә чыга. Көттереп кенә 2 бала алып кайталар, тик бергә тәрбияләргә язмый, Хәкимҗан абый бик яшьли үлеп китә. Мөнирә апа балаларын берүзе тәрбияләп үстереп белем бирә, кеше итә.

Хәзерге вакытта Мөнирә апа Теләче районы Теләче авылында малае Айрат һәм кызы Энҗе гаиләсендә гомер кичерә.

# Гарипов Миңнулла Гариф улы



Гарипов Миңнулла Гариф улы 1934 нче елның 14 нче апрелендә Түбән Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Балачагы авыр сугыш елларына туры килә аның. Ул вакытта ашарга җитмигән. Черек бәрәңге белән кычыткан ашаганнар, ул вакытта әле кычыткан да булмаган. Өйгә ягарга утын юк, салкын өйдә утырганнар.

Авыр еллар булуга карамастан, Миңнулла абый 7 класс белем алган. 1953-56 нчы елларда армиядә хезмәт иткән. 1956 нчы елдан колхозда шофер булып эшли башлаган.

1959 нчы елда Рәхимә апага өйләнә Миңнулла абый. Аның белән 3 малай, 1 кыз тәрбияләп үстерәләр.

1994 нче елда Миңнулла абый лаеклы ялга чыга.

Бүгенге көндә җәмгәте Рәхимә апа белән Түбән Шытсу авылында тигезлектә гомер итәләр.

# Гыйбадуллина (Әхмәтвәлиева) Фәймә Габделхак кызы



Гыйбадуллина (Әхмәтвәлиева) Фәймә Габделхак кызы 1939 нчы елның 14 нче сентябрендә Югары Шытсу авылында дөньяга килә. Әтисе Габделхак Әхмәтвәли улын 1941 нче елда сугышка алалар. Бу вакытта Фәймә апага нибары 2 яшь кенә була.

Габделхак абый отделение командиры дәрәҗәсенә күтәрелә, сугыш кырында күрсәткән батырлыклары өчен бик күп орден-медальләр белән бүләкләнә. Туган якларына ул яраланып кайта. Ул 1960 нчы елның 11 нче ноябрендә вафат була.

Фәймә апа сугыш елларында Саба районы Керәнле авылында әбиләрендә тора. 1947 нче елда 8 яшендә укырга керә. 7 класс белем ала.

“Мәктәптә укудан бушаган араларда без дә колхоз эшеннән кайтып керми идек. Кечкенәдән чалгы белән печән дә чаптык, арба да тарттык, урманнан утын алып кайту да без балалар өстендә иде. Әле аның ачлыгы үзәккә үтте,” – дип искә ала Фәймә апа.

1968 нче елның 15 нче февралендә Фәймә апа кияүгә чыга һәм Арча районында яши башлый. Бирегә фермага терлек үрчетүче булып эшкә урнаша.

1990 нчы елның 1 нче гыйнварында, ире үлеп бер ел торганнан соң, Фәймә апа Югары Шытсу авылына әйләнеп кайта. Колхозда дуңгызчылык фермасына эшкә урнаша һәм лаелы ялга чыкканчы шунда эшли.

Бүгенге көндә Фәймә апа Югары Шытсу авылында гомер итә.

**Гыйләҗиева Зөлхәбирә Гыйләҗетдин кызы**




Гыйләҗиева Зөлхәбирә Гыйләҗетдин кызы 1933 нче елның 18 нче маенда Бигәнәй авылында дөньяга килә. Гаиләләре урта хәлле була. Ул дүртенче сыйныфка кадәр белем ала. Әтисе колхозда җитәкче булып эшли. Зөлхәбирә апага сигез яшь булганда сугыш башлана. Әтисен сугышка алалар һәм ул сугыш кырында һәлак була.

Сугыш вакытында төрле эшләрдә катнашалар: урак уралар, атлар карыйлар, көлтә бәйлиләр. Ул вакытта тормышлар авыр була: ашарга юк, кияргә юк.

1958 нче елда Югары Шытсу авылына Хатип исемле егеткә кияүгә чыга Зөлхәбирә апа. Аларның бер-бер артлы дүрт балалары туа. Ләкин аларны бергәләп үстерергә насыйп булмый. Кече малаена 53 көн булганда ирен яшен суга. Зөлхәбирә апа берүзе дүрт баланы аякка бастыра. Хәзер алар бар да тормышта.

Бүгенге көндә Зөлхәбирә апа кече улы белән Югары Шытсу авылында тора.

# Гыйлемханова (Әхмәтвәлиева) Бибинур Гәптелгани кызы



Гыйлемханова Бибинур Гәптелгани кызы 1935 нче елның 13 нче сентябрендә Югары Шытсу авылында туа. Аңа сугыш башланганда 5 яшь була. Әтисе сугышка китә.

1943 нче елда башлангыч класска укырга керә Бибинур апа. Ләкин озаклап укырга насыйп булмый, 1946 нчы елда сарык фермасында эшли башлый. Җиңү көнен сөенеп, зур өметләр белән каршы ала Бибинур апа. Әтисе дә сугыштан исән-сау әйләнеп кайта.

1960 нчы елда авылдашы Сабирҗан абыйга кияүгә чыга ул. Аның белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында гомер итәләр.

“Сугыш афәтен башка күрергә язмасын. Киләчәк буынга тыныч, имин тормыш телим. Мул тормышларының кадерләрен белеп яшәсеннәр иде,” – дип тели Бибинур апа.

# Гыйлемханов Сабирҗан Гыйлемхан улы



Гыйлемханов Сабирҗан Гыйлемхан улы 1934 нче елның 15 нче апрелендә Югары Шытсу авылында туа. Әтисе Гыйлемхан абый сугышка китә һәм әйләнеп кайтмый.

Сабирҗан абый 1942 нче елда укырга керә.

1953-56 нчы елларда Совет армиясе сафларында хезмәт итә. Хезмәттән кайткач, колхозда төрле эшләрдә эшли. Ләкин Сабирҗан абыйның бик тә механизатор булып эшлисе килә. Ул хыялы аны Кукмара районы Янил авылындагы механизаторлар әзерли торган училищага алып килә. 1964-65 нче елларда ул механизаторлыкка укый. 1965 нче елда ул механизатор булып эшли башлый. Пенсиягә чыкканчы ул бу һөнәреннән аерылмый. Пенсиягә чыккач та, Сабирҗан абый тик ятмый, урманчылыкта бура бурый. 1997 нче елдан Югары Шытсу авылында мулла вазифасын башкара.

Хатыны Бибинур апа белән өч ул үстергәннәр. Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында олы уллары Фәнис һәм киленнәре Гөлназ белән тату, матур тормышта яшиләр.

# Гыйльманов Фәрит Шәрәфи улы



Гыйльманов Фәрит Шәрәфи улы 1941 нче елның 21 нче июлендә Елыш авылында гади колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Гаиләдә 4 бала үсәләр. Әти-әнисе көне-төне колхозда эшләгәннәр. Эшләсәләр дә, акча ала алмаганнар, хезмәт көне генә язылып барылган.

“Өскә кияргә күлмәкләребез, аяк киемнәребез булмаган. Яланаяк йөреп үскәнбез. Әни әйткәнчә, черек бәрәңге һәм кычыткан ашап үскәнбез. Шул авырлыкларга да карамастан, безне тәрбияләгәннәр, ач-ялангач итмәгәннәр,”- дип искә ала Фәрит абый.

Фәрит Шәрәфи улы 7 класс белем ала. 1955 нче елдан колхозда төрле эшләрдә эшли. 1962-65 нче елларда армия сафларында хезмәт итеп кайта. 1967 нче елның 26 нчы февралендә Кукмара районы Туембаш авылы кызы Саймә белән гаилә корып, 2 бала үстерәләр.

“Буш вакытларымда кешеләргә тәрәзә рамнары ясадым. Колхоз эшендә дә тырышып эшләдем. Шул тырышлыгым өчен 1975 елда **“Мактаулы колхозчы” исеме**н бирделәр,” – дип сөйли Фәрит абый.

Бүгенге көндә ул Елыш авылында гомер итә.

# Гыймадиева Нурзия Билал кызы



Гыймадиева Нурзия Билал кызы 1935 нче елның 17 нче августында Югары Шытсу авылында дөньяга килә. Алар гаиләдә 4 бала үсәләр, Нурзия апа иң кечкенәсе була. Балачагы авыр сугыш елларына туры килә аның. Әтисе сугышка китә, аннан яраланып кайта.

Нурзия апа 7 класс белем ала. Алга таба укуын дәвам итәргә мөмкинлеге булмый Нурзия апаның. Яшь чагыннан авыр хезмәт юлын башлап җибәрә. Аннан соң гомер буе фермада эшли. Аның бик күп **Рәхмәт хатлары, грамоталары** бар.

Тормыш иптәше Имаметдин абый белән гаилә корып, 4 малай тәрбияләп үстерәләр. Нурзия апа яшьли тол кала, бөтен авырлыкны үз җилкәсендә күтәрә.

Бүгенге көндә улы Айдар белән килене Рәзифә гаиләсе белән Югары Шытсу авылында яши. Ул бүгенге тормышыннан бик канәгать.

# Дәүләтшина Тәслимә Файзрахман кызы



Дәүләтшина Тәслимә Файзрахман кызы 1937 нче елның 18 нче февралендә колхозчы гаиләсендә туа. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 4 яшь була. Тәслимә апа 7 сыйныф белем ала.

1957 нче елда Югары Шытсу авылына килә һәм шунда Нурмөхәмәт абый белән гаилә коралар. Алар 11 бала тәрбияләп үстергәннәр. Хәзерге көндә аларның 9 исән-сау, үз тормышлары белән яшиләр.

Тәслимә апага тормыш алып бару бик җиңелдән бирелмәгән. Элекке вакытта басудагы эшләр бөтенесе дә кул белән эшләгәннәр. Тормыш иптәше белән чөгендер басуында да, борчак басуында да эшләгәннәр, өйдә мал-туарлар асрап көн күргәннәр.

Бүгенге көндә Тәслимә апа Югары Шытсу авылында бәхетле картлык кичерә.

# Җәләлиев Гыйлаҗетдин  Гыймадетдин улы



Җәләлиев Гыйлаҗетдин Гыймадетдин улы 1940 нчы елның 19 нчы декабрендә Саба районының Югары Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә туа. Гаиләдә булган 4 малай, 1 кыз - барысы да башлангыч классларны авыл мәктәбендә укый, Түбән Шытсу җидееллык мәктәбендә  җидееллык белем ала. Гыйлаҗетдин  абыйның әтисе колхозда бригадир булып эшли. Сугыш башланганда да колхоз басуында була. Аңа урып-җыю эшләре беткәнче тими торырга булалар. Ләкин, күп тә үтми, чират Гыймадетдин абзыйга да килеп җитә. Аңа үзе җигеп йөри торган аты белән барырга приказ килә, 3 нче бригаданың иң шәп аты белән дә, Гыймадетдин абзый белән дә елый-елый саубуллашалар.

Бердәнбер көнне Гыйлаҗетдин абый гаиләсенә кайгылы хат килеп төшә. Белоруссияне азат итү өчен көрәшләрдә Гыймадетдин Җәләлетдин улының һәлак булуы турында язылган була анда.

Гыйлаҗетдин абый, мөмкинлекләре булмау сәбәпле, урта белем ала алмый. 10 классны кичке мәктәптә укып тәмамлый. 1957 нче елда авылның клуб мөдире итеп куялар, шул ук вакытта хат ташучы итеп тәгаенлиләр. 1968 нче елда Казанда художник-оформительләр курсында укый ул. Шул ук твакытта комсомол оешмасы секретаре, “Игенче даны” стена газетасында редактор, район газетасы хәбәрчесе булып эшли.

Күп кенә мактау грамоталары белән бүләкләнә Гыйлаҗетдин абый. "**Хезмәт ветераны**" исеме бирелә. Гаиләсе, малае бар. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.

# Зәкиҗанова (Сабирова ) Мәрхәбә Сабир кызы



Зәкиҗанова Мәрхәбә Сабир кызы Саба районы Мамалай авылында 1935 нче елның 25 нче августында эшчеләр гаиләсендә туа. Шул авылның мәктәбендә дүрт ел белем ала.

1940 нчы елда Бөек Ваташ сугышынын башлануын әти-әнисеннән ишеткән. Сугышның үзен күреп белмәсә дә, авырлыкны, ачлыкны - барысын да кичергән. Әле биш кенә яшьлек нәни бала, бер ипи сыныгы бирсеннәр дип, апалары белән уракка бара торган була. Җиргә чәчелгән башакларны тырма белән җыйганнар. Кар эреп бетәр-бетмәстән, абыйсы белән өшегән бәрәңге җыярга чыкканнар. Шул бәрәңгедән апалары күмәч пешергән.

Мәрхәбә апа ягыннан сугыш кырына көрәшергә китүче булмаган. Әтисен Казанга ат белән эшкә җибәргәннәр. Ул елларда дөреслек булмау аркасында, аны төрмәгә утыртканнар. Кызганычка каршы, ул аннан исән килеш кайта алмый. Мәрхәбә апа этисез кала.Апаларын да урман кисәргә, окоп казырга алып киткәннәр.

Бер аяз көндә авыл кешеләре шау-шу килгән, куанышканнар. Ул сугыш бету көне булган. Сугыш беткәч тә, аның салкын җилләре исүдән туктамый. Тракторда эшләүчеләргә көянтә белән су ташыган, пулугар булып та йөргән Мәрхәбә апа. Ул вакытта комбайннар салам төшерә алмаганнар, тимергә бәрелә-бәрелә, кара янып, комбайннан саламнар да төшергән ул.

Түбән Шытсу авылы егете Сабирҗанга кияүгә чыга Мәрхәбә апа. Өч балалары туа.

Бүгенге көндә Мәрхәбә апа Түбән Шытсу авылында яши.

# Зиннәтуллина Тәслимә Сафиулла кызы



Зиннәтулина Тәслимә Сафиулла кызы 1942 нче елның 27 нче мартында дөньяга килә. Әтисе Гарипов Сафиулла Сталинград сугышында хәбәрсез югала. Әнисе 4 бала белән торып кала, шуларның өчесе, төрле сәбәпләр аркасында, дөнья куя.

“Безгә бик авыр булды, ачлыкны да күрдек, хәер дә сораштык,” – дип искә ала Тәслимә апа

Ул башта Кукмарада, аннан соң Казанда бала карый. Паспорт алгач, Чиләбегә китә. Анда төрле оешмаларда эшли, тормышка чыга. Ире авыру сәбәпле, Таджикстанга күченәләр. Анда җыештыручы , бала караучы, хат ташучы булып эшли Тәслимә апа. 1991 нче елда Саратовка күченә. Анда төрле эшләрдә эшли. 2002 нче елда Югары Шытсу авылына кайта һәм бүгенге көндә дә биредә яши.

**“Ветеран-труда” медале** бар.

# Ибраһимова (Фәйзиева) Мәмдүмә Фәйзи кызы





Ибраһимова (Фәйзиева) Мәмдүмә Фәйзи кызы 1941 нче елның 8 нче июнендә Югары Шытсу авылында туа. Ул 7 класс белем ала. 2 классны Югары Шытсуда, ә 5 классны Түбән Шытсуда укый. Сугыш башланганда ул туган гына була. Сугыш башлануга әтисен, Дәүләтшин Фәйзине, сугыш кырына, ә әнисен окоп казырга алып китәләр. Сугыш беткәч, әтисе кайта. Йөзе бик каты яраланган була.

«Әби алабутадан пәрәмәч пешерә иде. Безнең ул вакытта сыер бар иде.Ул сөт биреп тормаса,без ачтан үлгән булыр идек.Шул сөттән без ашлар пешереп ашадык,»-дип сөйли Мамдума апа.

Ул 7 нче классны тәмамалагач, 10-12 ел фермада, аннары соң стройкада эшли. Яхшы эше өчен аңа шулай ук медаль бирелә.

Тормыш иптәше Мансур абый белән алар Югары Шытсуда бәрәңге чүпләгәндә танышканнар. Берничә елдан соң өйләнешеп, гаилә корганнар. Сугыш беткәч, балалар үстергәннәр, бергә эшләп яшәгәннәр.

«Бүгенге көндә без бик яхшы яшибез. Хәзер нәрсә теләсәң, шуны сатып алып була. Шөкер, яшьлегебездә авырлыклар кичерсәк тә, картлыгыбыз рәхәт тормышта уза. Яшьләр бу тормышның кадерен белсеннәр иде,” – дип тели Мәмдүмә апа.

# Ибраһимов Мансур Ибраһим улы





Ибраһимов Мансур Ибраһим улы 1938 нче елның 30 нчы маенда Түбән Шытсу авылында туа. Шушы авылда ук 7 класс белем ала. Сугыш башланганда аңа әле 3 яшь була. 1941 нче елда аның әтисен, Ибраһимов Ибраһимны, сугышка алып китәләр, ә әнисе, Галимуллина Гыйлембикә, авылда эшләргә кала. Сугыш беткәч, әтисе Ибраһим абый бер күзсез кайта.

«Бары тик 1967 елда гына тамак туя башлады. Ул вакытта безгә икмәк бирә башладылар,» - дип исенә төшерә Мансур абый.

Ул Арча училищесында машинистка укый. Гомере буе тракторист, комбайнер булып эшли. 1957-1960 нчы елларда армиядә хезмәт итә. Мактаулы эше өчен аңа **Ленин исемендәге медаль** бирелә.

Бүгенге көндә хатыны Мәмдүмә апа белән Түбән Шытсу авылында яшиләр.

# Ибраһимова (Хайруллина) Нурания Шәрифулла кызы




Ибраһимова Нурания Шәрифулла кызы 1939 нчы елның 16 нчы мартында Түбән Шытсу авылында туа. Әтисе - Шарифулла , әнисе - Гәндәлиф. Нурания апа әтисе Шарифулла абзыйны сугышка озатканын төш шикелле итеп кенә хәтерли. Энесе бу авырлыкларны күтәрә алмыйча, үлеп китә. Әнисен кыш көне урман кисәргә алып киткәннәр, аннан ул аяксыз кайткан. Нурания апа барлык хуҗалык эшләрендә дә, колхоз эшләрендә дә катнашып, эшләп үскән. Ашарларына булмаган диярлек, ачлык булган: аларга черек бәрәңге, кычыткан ашарга туры килгән. “Сугышта җиңүне кешеләр урамнарда җырлый-җырлый бәйрәм итүеннән белдек,” - дип сөйли Нурания апа.

Ул 7 класс белем ала. Алга таба укуын дәвам итәргә мөмкинлеге булмый. Нурания апа фермага сыер саварга керә. 1961 нче елда Елыш авылы егете Хәмит абыйга кияүгә чыга. Алар 3 малай үстерәләр. Елышка килгәч тә, фермада эшли.

Нурания апа бүгенге көндә Елыш авылында яши. Тормыш иптәше Хәмит абый 2011 елда вафат булган.

# Минибаева (Якупова) Суфия Әскәр кызы



Минибаева Суфия Әскәр кызы 1939 нчы елның 1 нче июлендә Елыш авылында колхозчы гаиләсендә туа. Аңа 2 яшь вакытта әтисе белән абыйсы сугышка китәләр. Абыйсы сугыш кырында үлеп кала.

Суфия апа Елыш мәктәбендә 4 класс белем, аннан соң Түбән Шытсу мәктәбендә 7 класс белем ала.

“Сугыш елларында булган ачлык-ялангачлык, чарасызлыкны сөйләп-аңлатып бетерерлек түгел,” – дип авыр көрсенә Суфия апа.

1959 нчы елда Көек (Сат-Ключ) авылы егете Вакыйф абыйга кияүгә чыга ул. 1960 нчы елда Себергә китәләр. 9 елдан соң Үзбәкстанга күченәләр. Анда да тормыш җиңел булмый. 10 бала үстерәләр. 1994 нче елда туган авылларына күченеп кайталар.

Суфия апа бүгенге көндә дә күп итеп мал-туар асрый. Оныкларын да эшкә өйрәтә.

“Балаларыма, оныкларыма тынычлык, сабырлык, мәрхәмәтлелек, гаделлек, үз илләрен яратуларын, илгә лаеклы булып үсүләрен телим. Беркайчан да сугыш афәтен күрергә язмасын,” - ди ул.

# Миннебаева (Исмәгыйлова) Филзия (Флүрә) Мөхәммәтхан кызы



Миннебаева Филзия Мөхәммәтхан кызы 1936 нчы елның 15 нче гыйнварында Теләче районы Җәнәй (Сос-Мысь) авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. Башлангыч белемне Җәнәй башлангыч мәктәбендә, ә җидееллык белемне Төбәк мәктәбендә ала.

Филзия апаның әтисе Мөхәммәтхан исемле булган. Әтиләрен бик күп күз яшьләре түгеп сугышка озатканнарын хәтерли ул. Алар алабута ипиләре ашаганнар, ашларны үләннәрдән пешергәннәр, басулардан черек бәрәңгеләр җыеп, аннан кәлҗемә ясап пешереп ашаганнар. Алар гел сугыш бетәр, әти кайтыр дигән өмет белән ышанып яшәгәннәр. Ул вакытта аякларга аяк киеме дә булмаган, чабата кигәннәр, өскә кияргә дә ике-өч кешегә бер кием булган. Ләкин әтиләре сугыштан әйләнеп кайтмый. 3 бала әтисез үсә. Филзия апага авыр эшләрдә эшләргә туры килә.

1961 нче елда Елыш авылы егете Гомәр абыйга кияүгә чыга. Тормыш иптәше белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Колхозда төрле эшләрдә эшлиләр.

Бүгенге көндә Филзия апа кече улы Наил белән Елыш авылында гомер кичерә.

# Мифтахов Зөфәр Минһаж улы



Мифтахов Зөфәр Минһаж улы 1940 нчы елның 22 нче июлендә Елыш авылында туа. Сугыш башланганда аңа 1 яшь була. Гаиләдә 2 бала үсәләр. Әтиләре сугышка китә, ләкин әйләнеп кайтмый.

“Әниебез көне-төне басуда булган. Без аларның артыннан тырма белән башак җыеп йөрдек. Ашарга ипи юк иде. Өшегән бәрәңге ашадык. Он заты күрмәдек. Өскә-башка юк, киндер күлмәк киеп йөри идек. Аягыбызда чабата. Көчебез җитмәсә дә, печән чаптык,” – дип искә ала Зөфәр абый.

Җиде класс белем ала ул. 1963 нче елда Көек (Сат-Ключ) авылы кызы Минненурга өйләнә. Аның белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Колхозда тракторда, фермада эшли Зөфәр абый. Соңгы елларда көтү көтә. 2000 нче елда пенсиягә чыга.

“Моннан соң балаларга, оныкларга сугышларны күрергә язмасын. Илләр тыныч, күкләребез аяз, йөзләребез шат булсын”-дип сүзен тәмамлады Зөфәр абый.

Ул бүгенге көндә кызы Фәридә белән Елыш авылында яши.

# Мөбәрәкшина (Фәрхуллина) Гәмбия (Мәгъдәния) Фәрхулла кызы




Мөбәрәкшина Гәмбия Фәрхулла кызы 1944 нче елның 10 нчы августында Югары Шытсу авылында туа. Әтисе Заһидуллин Фәрхулла гомере буе фермада мөдир булып эшли. Әнисе Бәдигөл апа колхозда төрле эштә эшли. Гәмбия апага 1,5 яшь булганда, әнисе авырып үлеп китә. Әнисеннән өч кыз ятим калалар.

Әтисе 1941 нче елда Бөек Ватан сугышына китә. 1943 нче елның ноябрь ахырында каты яраланып, сугыштан кайта. Сугыш беткәч, әтиләре Җәмилә исемле кызга өйләнә. Үги әниләре тәртипле, акыллы, эшчән була. Ятим балабларны какмый, үз балалары кебек карый.

Гамбия апа 4 нче класска кадәр Югары Шытсу мәктәбендә башлангыч белем ала. Ул бик тырышып укый, 10-11 яшьләрдә колхоз эшенә йөри башлый. 7 нче классны бетерүгә, Югары Шытсу фермасына дуңгыз карарга эшкә керә. Югары Шытсуның уңган, чибәр егете Мөбәрәкшин Шәймөхәмматкә 1963 нче елда тормышка чыга.

Әтисе пенсиягә чыккач, Гамбия апаны Югары Шытсу фермасына ферма мөдире итеп куялар. Һәр елны терлекчелек буенча ферма коллективлары арасында җиңеп чыккан өчен, Гамбия апа **колхоз идарәсе, партком, профсоюз исеменнән Мактау грамоталары белән бүләкләнә һәм районның Мактау тактасында тора.** Шулай ук тырыш һәм намуслы хезмәте өчен, **ВДНХның көмеш медале**, бик күп **мактау грамоталары, дипломнар, истәлекле бүләкләр** белән бүләкләнә.

1986 нчы елдан башлап, колхоз ашханәсендә өлкән пешекче булып эшли. Һәркемне тәмле ашлары, ризыклары белән сыйлый Гәмбия апа.

Хәзер ул лаеклы ялда. Дуслары, күршеләре, якыннары белән аралашып яши.

# Муллахметова (Гатина) Гыйльминур Шәймәрдән кызы



Муллахметова Гыйльминур Шәймәрдән кызы 1940 нчы елның 16 нчы февралендә Түбән Шытсу авылында дөньяга килә. Бөек Ватан сугышы башланганда Гыйльменур апага бары тик 1 яшь кенә була. Ләкин ике ил арасында канкойгыч сугыш барганда аның гаиләсе Сахалинда яши башлый.

“Сугыш башланган вакытта, без гаиләбез белән Сахалинга киттек. Әтине сугышка озаттык. Шулай бер әнигә 3 бала калды. Әни әти янына барып йөрде, ашарына да ризыклар алып барды. Әтием – Шәймәрдән, пограничник була. Дәһшәтле елларга эләксәк тә, түздек. Ашарыбызга булмаса да, зарланмадык,” – ди Гыйльминур апа.

Инде, ниһаять, ничә еллар буе көткән, халык йөрәгендә яшәгән көн - Җиңү көне дә килеп җитә. Бу гади сүзләр белән генә җиткереп бетерә алмаслык, чып-чын бәхет, зур сөенеч, олы куаныч була. Гыйльминур апаның әтисе үз гаиләсенә, үз өенә кире әйләнеп кайта. Сугыш бетеп, Сахалинда 7 ел торганнан соң, алар кире Түбән Шытсуга кайталар. Кайтканнан соң, Гыйльминур апа укый башлый. Укып бетергәннән соң, нииди генә эшләрдә эшләми: колхозда умарта, бозаулар карый, озак еллар хуҗалыкта сөт җыя. Соңгы елларда мәктәптә пешекче, клубта җыештыручы булып эшли..

1961 нче елның 1нче январендә Гыйльминур апа белән Марсель абый бер-берсен табып, кавышалар, гаилә корып яши башлыйлар. Бүгенге көндә, аларның 3 балалары бар. 8 оныкка дәү әти белән дәү әни булып, Түбән Шытсу авылында исән-сау яшиләр.

# Муллахметов Марсель Нуриәхмәт улы



Муллахметов Марсель Нуриәхмәт улы 1939 нчы елның 16 нчы февралендә Түбән Шытсу авылында туа. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа нибары 2 яшь кенә тулган чаклар була. Марсель абый сөйләгәнчә, бик бәләкәй булу сәбәпле, алар олыларча зур эшләр башкара алмаганнар.Марсель абыйның әтисе – Нуриәхмәт, сугышка киткәннән соң, гаиләдә алар әниләре белән 3 бала тәрбияләнәләр.

“Бу еллар, минем тормыштагы иң авыр елларның берсе булды. Бар халык куркуга салынган. Хәзерге вакыттагы кебек табыннар төрле-төрле тәм-томнар белән тулып тормый иде. Алабута, кычыткан ашларын ашап үстек. Бер телем ипи дә безгә бик кадерле иде! Киемнәребез бүгенге көндәге кебек матур, затлы булмады, ә киресенчә, өсләребездә иске-москы киемнәр, аякта чабата иде,” – дип искә ала Марсель абый.

Сугыш беткәннән соң, тыныч илдә, тыныч тормышта Марсель абый 1951нче елда Таджикстанга китә, аннары 1954 нче елда әби-бабасы янына кайтып, Түбән Шытсуда үсә. Кире туган авылына кайтканнан соң, 5 нче класста укый башлый, 7 нче классны укып бетергәч, 1959 нчы елда урманчылык белән шөгыльләнә башлый. Ә алга таба колхозда: 17 ел тракторда, 23 ел терлекчелектә эшли.

Тормыш иптәше Гыйльминур апа белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр: кызлары Фидания – 1961 нче елның 7 нче декабрендә, уллары Раиф – 1964нче елның 31нче январендә, кызлары – Ләйсән 1978 нче елның 5 нче октябрендә дөньяга киләләр.

Хәзерге тормыштан канәгать булып, Аллага Шөкер дип, алар шушы кайгысыз тормышта бернәрсәгә зарланмыйча исән-имин яшәп яталар. Һәм шулай Гыйльминур апа белән Марсель абыйга алга таба да озак еллар яшәргә язсын!

# Мусина Сания Котдус кызы



Мусина (Хөсәенова) Сания Котдус кызы 1939 нчы елның 27 нче сентябрендә Саба районы Югары Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә туа. Бөек Ватан сугышы башлангач, әтисе Котдус 1942 нче елны фронтка китә. Ул вакытта Сания апага 2 яшь кенә була.

Сания апа башта Югары Шытсу башлангыч мәктәбендә 3 класс белем ала, аннары Түбән Шытсу җидееллык мәктәбендә укуын дәвам итә. Югары Шытсу авылында хәзерге мәчет булган урында башлангыч мәктәп эшләгән. Сания апа шунда укыган. Башлангыч сыйныфта ул вакытта Кәүсәрия, Асия исемле укытучылар укыткан.

1961 нче елда Сания апа Югары Шытсу авылы егете Мусин Малик белән тормыш корып җибәрә. 1963 нче елның 1 нче гыйнварында беренче балалары – Дания, 1964 нче елда - Гөлнур, 1968 нче елда - Илнур, 1974 нче елда Рәсимә дөньяга килә. Ире Малик абый “Беренче Май” колхозында инженер-механик булып, үзе башта колхозда төрле бригада эшләрендә, аннары Югары Шытсу балалар бакчасында 18 ел пешекче булып эшли Сания апа.

Хәзерге вакытта лаеклы ялда, балалары тәрбиясендә яши.Бик ярдәмчел, кешелекле, кече күңелле, ил-көн яңалыклары белән хәбәрдар. Кызганычка каршы, эш урыныннан, колхоздан мактау грамоталары юк. Гади тормыш юлы үткән кеше ул Сания апа.

# Набиуллина Миңсылу Сөнәгать кызы

Набиуллина Миңсылу Сөнәгать кызы 1942 нче елның 3 нче сентябрендә Түбән Шытсу авылында дөньяга килә. 1941 нче елда әтисе Сөнәгать сугышка китә, 1943 нче елда каты яраланып кайта.

Миңсылу апа 7 класс белем ала. Мәктәптә укыган чорда урак урган, көлтә бәйләгән, фермада эшләгән ул. Черек бәрәңге, какы, кузгалак, алабута, йонлы күшә, баллы тамыр, бәрәңге сабагы, кычыткан, чыпчык кузгалагы, миләш ашаганнарын бик көрсенеп искә төшерә

Миңсылу апа 42 ел фермада сыер сава. Ул үз эшен яратып башкара. Бик күп **грамоталары**, **Рәхмәт хатлары** белән бүләкләнә.

Миңсылу апа Түбән Шытсу авылы егете Рифнур абыйга кияүгә чыга. Алар 5 бала үстерәләр.

Бүгенге көндә Рифнур абый бакый дөньга күчкән. Миңсылу апа кечкенә улы Ильмир белән яши.

# Нотфуллина (Билалова) Гөләмдә Билал кызы

Нотфуллина Гөләмдә Билал кызы 1942 нче елның 1 нче маенда Түбән Шытсу авылында туа. Әтисе Билал, әнисе Фатыйма 4 кыз, 2 малай үстерәләр.

Әтисе Билал абый 1942 нче елда сугышка китә. Гөләмдә апа, әтисе сугышка киткәч, 2 айдан соң туа. Сугышка кадәр Билал абый гаиләсе Донбасста яши. Сугыш башлануга, гаиләсен авылга кайтара, аннан үзе сугышка китә.

6 баланы үлемнән саклап калу өчен, әниләре бик тырыша. Иске материалдан киемнәр тегә, җәй көне балалары белән төрле үләннәр, көз көне колхоз басуыннан черек бәрәңге җыя. Билал абый сугышта бик каты яралана. Бик озак госпитальдә ята. 1944 нче елда бер кулсыз булып авылга кайта.

Гөләмдә апа 1957 нче елда 7 нче классны тәмамлый. Сарык фермасына эшкә керә. Анда 2 ел эшләгәннән соң , Түбән Шытсу фермасына сыер савучы булып эшкә алалар.

1965 нче елның августында КПСС райкомы һәм район Советы башкарма комитеты Гөләмдә апа исеменә котлау җибәрә. Терлекчеләр көнендә аңа **“Коммунистик хезмәт ударнигы” таныклыгы** тапшыралар.

Гөләмдә апа 1965 нче елда Казанга ВЛКСМның 18 конференциясенә Саба районыннан делегат булып бара. Ул анда космонавт Валентина Терешкова белән очраша.

Ул озак еллар авыл советы депутаты булып тора. Эшләгән дәвердә, ул бик күп грамоталар, дипломнар, кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә, **ВДНХның Көмеш медале**нә лаек була.

1965 нче елда, Түбән Шытсу егете Индус абыйга тормышка чыга Гөләмдә апа. Алар өч бала тәрбияләп үстерәләр. Гөләмдә апаның 5 оныгы бар.

Гөләмдә апа 1997 нче елда пенсиягә чыга. Бүгенге көндә Түбән Шытсу авылында гомер итә.

**Рамазанова (Ибраһимова)   Нәзирә  Ибраһим кызы**





Рамазанова Нәзирә Ибраһим кызы 1940 нчы елның 6 нчы ноябрендә Түбән Шытсу авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе - Ибраһим, әнисе – Гыйлмениса исемле була. Әтисе сугышка киткәндә Нәзирә апага нибары 8 ай булган.

“Безнең бөтен байлыгыз сыер булды. Шул сыер безне ачлыктан коткарды. Сыеры булмаган кешеләрнең ачлыктан шешенеп үлгән очраклары да булды. Без сыер сөте эчеп, үлемнән калдык. Сыерны саклап калу өчен уфалла арбасы белән алабута, кычыткан алып кайта идек. Сыерның бозавын хөкүмәткә җыйдылар,” – дип сугыш еллары хәтирәсен яңарта ул.

Нәзирә апаның әтисе дә, әтисенең абыйсы Әюп абый да сугыштан әйләнеп кайтмый. 7 класс тәмамлап, фермага эшкә керә. Аннары колхозда төрле эштә йөри. Күп еллык нәтиҗәле хезмәте өчен Мактау грамотасы белән бүләкләнә. 1964 нче елда Елыш авылы егете Рамазанов Зәкиҗанга кияүгә чыга ул. Тормыш иптәше белән берсеннән берсе акыллы, эш сөючән өч ул тәрбияләп үстерәләр.

“Тик бусагабыздан кара кайгы керде. 2007 нче елда олы улым Альберт, 2010 нчы елда, авырып, тормыш иптәшем Зәкиҗан, 2014 нче елда кечкенә улым Әхкәм үлеп китте. Яшәү дәверен дә әдәм баласы ниләр генә күрми! Ярый әле Ходай матур тормышны картлык көнемә биргән,” - дип, дога кыла Нәзирә апа.

# Рахиев Нуретдин Рахый улы



Рахиев Нуретдин Рахый улы 1940 нчы елның 25 нче апрелендә Түбән Шытсу аылында туа. Аңа 1 яшь булганда, Бөек Ватан сугышы башлана. Әтисе 1941 нче елда сугышка китә. 2 бала әнисе җилкәсенә утырып калалар. Әнисе көне-төне колхозда эшли. Нинди авыр хезмәт башкарылса да, ул заманда акча түләнелмәгән, хезмәт көне генә язылып барылган.

Нуретдин абыйларның өсләренә кияргә күлмәкләре, аяк киемнәре булмаган. Яланаяк йөреп үскәннәр. Әнисе әйткәнчә, черек бәрәңге һәм кычыткан ашап үскәннәр. Шул авырлыкларга да карамастан, әниләре аларны тәрбияләгән, ач-ялангач итмәгән. Сугыш беткәч тә авыр тормыш дәвам иткән. Нуретдин абыйның әтисе сугыштан әйләнеп кайта алмаган.

Нуретдин абый гомере буе колхозда эшли. Алар хатыны Нурзидә апа белән 6 бала тәрбияләп үстерәләр.

Бүгенге көндә Нуретдин абый Түбән Шытсу авылында гомер итә.

## Ризванова Расиха Шәяхмәт кызы



Ризванова Расиха Шәяхмәт кызы 1936 нчы елның 6 нчы октябрендә Әлмәт районы Бишмунча авылында туа. Казан Дәүләт педагогия институтын тәмамлый, математик. 1956 нчы елда Саба районы Түбән Шытсу авылында эшли башлый. 1956-61 нче елларда пионервожатый хезмәтен дә башкара. Түбән Шытсу авылы егете Сабуров Зиннур белән гаилә корып, 1 ул һәм 1 кыз тәрбияләп үстерәләр.

Расиха апа 1966-87 нче елларда “Башлангыч белем” җәмгыятенең җитәкчесе, лектор, политинформатор, агитатор, ата-аналар университеты җитәкчесе, хатын-кызлар советы члены, биш чакырылыш авыл советы депутаты, финанс-бюджет комиссиясе председателе булып тора. 1966-82, 1985-90 нчы елларда Түбән Шытсу мәктәбендә укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары була. 1984 нче елда Расиха апага “Укытучы-методист” исеме бирелә.

1986 нчы елда мәгариф работникларының Почет тактасына, Почет китабына кертелә. Район мәгариф бүлеге, Исполком һәм КПСС райкомы, республика һәм РСФСР “Белем” җәмгыяте тарафыннан бирелгән дистәләгән грамоталар белән бүләкләнә.

1991 нче елда пенсиягә чыга. Бүгенге көндә Расиха апа Түбән Шытсу авылында яши.

## Салихова (Идиятуллина) Сәрия Миннемөхәммәт кызы




Салихова (Идиятуллина) Сәрия Миннемөхәммәт кызы 1941 нче елның 6 нчы гыйнварында Миннемөхәммәт белән Мәрфуга гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Әтисе сугышта катнаша, бик күп орден-медальләр белән, ләкин яраланып, туган якларына әйләнеп кайта.

Сәрия апа башлангыч белемне Югары Шытсу мәктәбендә ала. 1955 нче елда Түбән Шытсу авылы мәктәбендә 7 нче сыйныфны тәмамлый. Шул ук елны бригадта, ашлык суыруда, фермада эшли башлый.

1963 нче елның июнь аенда Сәрия апа Казахстанга чыгып китә һәм Караганда шәһәрендә яши башлый. Башта төзелештә, 1978 нче елдан “Карагандинская Чулочно-носочная фабрика”да эшли. Биредә лаеклы ялга чыкканчы, ягъни 1996 нчы елга кадәр, армый-талмый хезмәт куя Сәрия апа. Эш стажы 37 елны тәшкил итә. Ул тырыш һәм нәтиҗәле хезмәте өчен 1975, 1978, 1989 нчы елларда **Почет грамоталары**на, **“Ударник коммунистического труда” значогы**на ия була.

Сәрия апа 1964 нче елның май аенда Саба районы Төбәк авылы егете Рафаэль Нәҗип улы белән гаилә коралар һәм ике кыз үстерәләр.

1998 нче елның 6 нчы сентябрендә Сәрия апа туган авылы Югары Шытсуга кайта. Авылга кайткач та, колхозда төрле эшләрдә эшли.

1996 нчы елда дин юлына баса ул. 2010 нчы елдан бирле авылда абыстай вазыйфасын башкара.

# Ситдикова Хәдичә Хисаметдин кызы




Ситдикова Хәдичә Хисаметдин кызы 1937 нче елның 8 нче июлендә Елыш авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. 7 класс белем ала. Әтисе сугышка киткәндә Хәдичә апага 4 яшь була.

“Сугыш вакытында без алдагы көнгә өмет белән яшәдек. Безнең әниебез бик тырыш, көчле рухлы иде, аның ярдәме белән без исән калдык. Сугыш башлангач, тормыш бик авыр булды. Ашарга табуы авыр булды. Ашарга яраклы яшеллек белән туклandык. Рәхәт вакытым булмады. Басуда кыр эшләрендә булыштык: җитен, борчак йолыктык, башак җыештык. 10 яшьтә пар ат җигеп ашлык ташырга булыштым.Фронтка дип май, йомырка, кипкән бәрәңге җибәрдек,” – дип хәтирәләрен яңарта Хәдичә апа.

Сугыш беткәнен әнисе хәбәр итә аңа. Тик әтисе белән күрешергә генә насыйп булмый.

Сугыштан соң да авырлыклар озакка бара. Тормыш йөге белемен арттырырга мөмкинлек бирми Хәдичә апага. Ул тавык фермасында, колхоздагы төрле эшләрдә эшли.

Хәдичә апа тормышка чыкмый. Озак еллар авыру әнисен карап соңгы юлга озата. Бүгенге көндә Елыш авылында ялгызы яши.

# Сөнгатуллина (Фәсхетдинова) Сания Гаптерәкыйп кызы



Сөнгатуллина (Фәсхетдинова) Сания Гаптерәкыйп кызы 1942 нче елның 1 нче октябрендә Түбән Шытсу авылында дөньяга килә. Сугыш чоры вакытында ул бишек баласы гына була. Сугышка гаиләдән этисе Гаптерәкыйп абый киткән. Һәм аңа кире туган авылына, гаиләсенә кайту насыйп булмаган. Ул Смоленск жирләрендә вафат булган.

Сания апа 1955 нче елда мәктәпне 7 сыйныф белем белән тәмамлый. Шуннан соң “Илшат” колхозында бозау караучы булып эшкә урнаша. 1 ел эшләгәннән соң аңа сарык караучы вазыйфасын тапшыралар. Үз эшен җиренә җиткереп, тәртип белән алып барганын күреп, колхоз рәисе Хуҗин Гобәйдулла абый Сания апага сыер савучы хезмәтен тапшыра. 1992 нче елның 1 ноябренә кадәр ул үз хезмәтенә тап төшермичә, намус белән эшли.

Сания Гаптерәкыйп кызы 1967 нче елның 13 нче апрелендә Сөнгатуллин Тимершаех Сөнәгать улы белән тормыш корып җибәрә.

“2 малай, 4 кыз үстереп бик матур тормыш иттек. Балаларым исән- сау булып , йөзебезгә кызыллык китермичә үстеләр, белем алдылар, һәрберсе үз юлларын сайлап, үз тормышлары белән яшиләр,” - ди Сания апа. Кызганычка каршы, 2012 елның 8 апрелендә тормыш иптәше Тимершаех абый вафат була.

Бугенге көндә Сания апа улы Әнәс, килене Алсу тәрбиясендә, оныклары Әнисә белән Алмазга кадерле, яраткан әби булып гомер итә. “Бүгенге тормышым белән мин бик канәгать . Бер Аллаһы Тәгаләгә мең-мең шөкер. Дөньяларыбыз имин, тыныч булуын, табыннарыбызның мул булып торуын телим “- ди Сания апа.

Сания апаның **“ Хезмәт даны” һәм “ Ана даны “ дигән медальләр**е бар.

# Тимербаев Равил Гафур улы



Тимербаев Равил Гафур улы 1941 нче елның 11 нче мартында Елыш авылында колхозчы гаиләсендә туа. Сугыш башланганда ул яшь бала була.Әтисе сугышка китеп, хәбәрсез югала. Әнисе Равил абыйга 7 яшь вакытта үлеп китә. Ул ятим кала. Аны ятимнәр йортына алырга киләләр. Ләкин бабасы Сәгыйть белән әбисе Мәрьямбикә аны үзләренә тәрбиягә алалар.

Равил абый Елыш башлангыч мәктәбен тәмамлагач, укуын дәвам итә алмый, чөнки өскә кияргә кием, ашарга да булмый. Ул фермага көтү көтәргә керә. Буш вакытларында атларга су ташый. Аны эш куркытмый. Ул бар тырышлыгын биреп эшли.

1962 нче елда Теләче районы Урта Мишә кызы Әлфинур апа белән тормыш корып җибәрәләр, 3 бала үстерәләр.

Пенсиягә чыканчы, Равил абый фермада эшли.

2001 нче елда аны ялгыз калдырып Әлфинур апа үлеп китә.

Хәзерге көндә ул ялгызы яши.

# Тимергалиева (Сафиуллина) Флера Сәетгәрәй кызы



Тимербаева (Сафиуллина) Флера Сәетгәрәй кызы 1938 нче елның 15 нче гыйнварында Балык Бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылында дөньяга килә. Әтисе милиция башлыгы булып эшләгәнлектән, төрле җирләрдә яшәргә туры килә аларның гаиләсенә.

Сугыш башлангач, әтиләре Сәетгәрәй абыйны сугышка алалар. Ул кире әйләнеп кайтмый, 1943 нче елда һәлак була.

“Без әнигә 6 бала калдык. Тормышлар авыр, ашарга юк. Бер әни генә белгәндер ул вакыттагы авырлыкны,” – дип искә ала Флера апа.

Сугыш беткәч, Флера апа гаиләсе белән Саба районы Югары Шытсу авылына кайтып урнаша. Гомеренең күп өлеше шушы авылда үтә Флера апаның. Түбән Шытсу авылының җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, авылда төрле эшкә йөри башлый ул.

1958 нче елда Югары Шытсу авылы егете Низаметдин Тимергали улына тормышка чыга. Аның белән 3 малай тәрбияләп үстерәләр.

1993 нче елда Флера апа лаеклы ялга чыга. Бүгенге көндә улларының ярдәмен тоеп, Югары Шытсу авылында бәхетле картлык кичерә ул.

# Усманов Миннәхмәт (Фаяз) Корбангали улы

Усманов Миннәхмәт (Фаяз) Корбангали улы 1940 нчы елның 27 нче мартында Тубән Шытсу авылында крестьян гаиләсендә туа. Сугыш башланганда Миннәхмәт абый бик кечкенә була. Сугышның ачысын, нәни булса да, ул да тоя. Сугышта әтисе Корбангали һәм әтисенең туганы Муса үлеп калалар. Сугыш беткәнен ат белән килеп, авылларга хәбәр итеп йөргәннәрен хәтерли әле Миннәхмәт абый.

Түбән Шытсу авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, алга таба укуын дәвам итәргә мөмкинлеге булмый аның. Сугышның дәһшәтле елларын бүген дә зур тетрәнү белән искә ала Миннәхмәт абый.

Хезмәт юлын бик яшьли башлап җибәрә ул. Миннәхмәт абый бик озак еллар колхозда тракторчы булып эшләгән. **Почётный грамоталар**ы бик күп.

2004 нче елның 6 нчы маенда беренче хатыны Рәйсә апа вафат булган. Бүгенге көндә Зөлфия әби белән гомер итәләр. Миннәхмәт абый Түбән Шытсу авылында муллалык вазыйфасын башкара.

# Фәләхов Гәләтдин Фәләхетдин улы



Фәләхов Гәләтдин Фәләхетдин улы 1937 нче елның 27 маенда Югары Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә туа. Сугыш башланганда аңа нибары 5 яшь кенә була.

“Урамдагы кешеләрнең сугыш турында сөйләшүләрен хәтерлим. Әтине сугышка кадәр сборга алганнар иде. Шуннан сугышка китте , пленга төште. Сугыш беткәч, авылга кайтты. Ләкин, пленда булу сәбәпле, аны төрмәгә алып киттеләр. Ул аннан авырып кайтты һәм озак та тормады, үлде,” – дип сөйли Гәләтдин абый.

Яшьтән ат саклый, төрле эшләрдә эшли ул. 1952-56 нчы елларда Бәләбәй шәһәрендә армиядә хезмәт итә. Аннан кайткач фермада, тракторда, комбайнда эшләргә туры килә. 1997 нче елда пенсиягә чыга. Пенсиягә чыккач та, 9 ел фермада каравылда тора.

Хатыны Шәмсемөхәммәтова Зәйнәп белән 5 бала тәрбияләп үстерәләр алар. Кызганычка каршы, Зәйнәп апа 1995 нче елның 20 нче сентябрендә каты авырудан вафат була.

Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында икенче хатыны Тәслимә апа белән гомер итә Гәләтдин абый.

# Фархуллина (Гатиятуллина) Сәлимә Галимҗан кызы



Фархуллина (Гатиятуллина) Сәлимә Галимҗан кызы 1942 нче елның 20 нче гыйнварында Түбән Шытсу авылында туа. Әтисе Гатиятулла 1941 нче елда сугышка китә һәм кире әйләнеп кайтмый. Әнисе Кәфия гомере буе колхозда эшли.


Барлык сугыш чоры балалары язмышы белән аваздаш Сәлимә апаның да язмышы. Сугыш елларында күргән авырлыклар өстенә, сугыштан соңгы еллар авырлыгы өстәлә. Әйе, этисез үсүнең ачысын әле дә оныта алмый ул. Сугыш чорына балачагы туры килгән Сәлимә апа тырыш, булдыклы, кешелекле, авырлыклар алдында каушап калмый торган олы йөрәкле, киң күңелле, сабыр һәм шул ук вакытта гади һәм тыйнак кеше.

Шундый авыр сугыштан соңгы чорлардан соң да ул үзенең тормышта юлын тапкан. Ул 7 класс белем ала. Соңыннан кичке мәктәпкә йөреп 11 классны тәмамлый. 1958 нче елда табельче булып эшли башлый.

Сәлимә апа Югары Шытсу авылы егете Василга кияүгә чыга. Аның белән 5 бала тәрбияләп үстерәләр.

Бүгенге көндә Сәлимә апа кадерле әни, кадерле дәү әни. 7 оныгы һәм 1 оныкчыгы бар.

# Фархуллин Васил Нотфулла улы



Фархуллин Васил Нотфулла улы 1939 нчы елның 21 нче маенда Югары Шытсу авылында туа.

Сугыш башланганда Васил абыйга 2 яшь була. Гаиләсе бик авыр хәлдә кала: ашарга юк, әтиләре сугышта. Бәрәңге дә юк, алабута җыеп, шуны ашыйлар. Мәктәптә укый башлагач, олыларга ияреп эшкә йөри башлый Васил абый. Сугыш беткәч, әтиләре исән-сау туган якларына әйләнеп кайта.

Васил абый 7 класс белем ала. 1957 нче елда Арчада комбайнерлыкка укый. 1959-62 нче елларда армия сафларында хезмәт итә. Шоферлыкка укый. 10 ел шофер булып эшли. Васил абый хайваннарны бик ярата. Шул сәбәпле, Ветеринария институтында укый. Лаеклы ялга чыкканчы ассимелятор булып эшли.

“Хәзер заманалар бик әйбәт. Безнең балаларга, оныкларга сугыш афәтен күрергә язмасын,” - дип тели Васил абый.

# Хабибуллин Азат Усман улы



Хабибуллин Азат Усман улы 1935 нче елның 1 нче апрелендә Елыш авылында ярлы крестьян гаиләсендә 4 нче бала булып дөньяга килә. Әтисе сугышка киткәндә аңа 6 яшь була.

“Әтиемне сугышка озатканымны хәтерлим. Мин җиңел генә силә дип йөртелә торган арбага утырып, дилбегәне тотып авыл башына кадәр бардым. Әти арбаның уң ягына утырган иде. Арттан кешеләр ияреп бардылар,” – дип хәтирәләрен яңарта Азат абый.

1947 нче елда Елыш мәктәбенә укырга керә ул.Бик авырлык белән укый. Ашарга-эчәргә юк, өскә, аякка кияргә юк. Бу юклык заманы аны Шытсу мәктәбенә дә озата килә. Уку чорында әтисе юклык үзен бик нык сиздерә.

4 классны бетергәч, ат җигеп печән, көлтә ташый Азат абый. Тартмалы арбага салып көнгә 15-16шар юл ашлык алып кайтканын бүгенгедәй хәтерли ул.

“Мин 7 нче классны 1953 елда тәмамладым. Алга таба укырга мөмкинлек булмады. Бик тә артист буласы килгән иде. Татар теле укытучыбыз Сания апа мине журналист булуымны теләде,” – дип сүзен дәвам итә Азат абый.

1957-60 нчы елларда ул Германиядә армия сафларында хезмәт итә. Армиядән кайткач, колхозда эшли башлый. Башта бригадир, аннан соң ферма мөдире була.

1964 нче елдан хат ташучы булып эшли башлый. 1980 нче **елда “Ударник коммунистического труда” медале** белән бүләкләнә. **Почет грамоталары, значоклары, рәхмәт хатлары** да бик күп Азат абыйның. Ленинның 100 еллыгына бирелгән медале дә бар.

Хатыны Халисә апа белән 2 кыз, 2 ул үстеәләр алар. Хәзерге көндә 4 оныгы, 1 оныкчыгы бар.

# Хайруллина (Юнысова) Сөембикә Хабибрахман кызы



Хайруллина Сөембикә Хабибрахман кызы 1935 нче елның 17 нче мартында Саба районы Югары Шытсу авылында дөньяга килә. Әтисе Юнысов Хабибрахман 1941 нче елда сугышка алына. Сөембикә апага бу вакытта 6 яшь була. Әтисенең япон гаскәрләренә каршы оборонада торулары турында язган хатларын хәтерли әле ул.

Сугыш беткәч, Хабибрахман абый исән-имин туган якларына әйләнеп кайта. Тик озак та тормый 1950 нче елның 22 нче декабрендә вафат була.

Сөембикә апа 1951 нче елда (аңа ул вакытта нибары 16 яшь була) колхозга эшкә кергән. Шул көннән башлап аның нәтиҗәле хезмәт юлы башланып китә. Озак еллар буе колхозда армый-талмый хезмәт куеп, 1989 нчы елның 23 нче гыйнварында лаеклы ялга чыга Сөембикә апа. Тырыш хезмәте өчен ике тапкыр **“Почет грамотасы”** белән бүләкләнә ул.

Сөембикә апа Югары Шытсу авылы егете Хайруллин Хәмзә абый белән тормыш кора. Аның белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Кызганыч, Хәмзә абый гына бүген арабызда юк.

Бүгенге көндә Сөембикә апа балаларының, оныкларының игелеген күреп, Югары Шытсу авылында бәхетле картлык кичерә.

# Хамидуллин Хәкимулла Гыйниятулла улы



Хамидуллин Хәкимулла Гыйниятулла улы 1933 елның 26 гыйнварында Түбән Шытсу авылында туа. Балачагы авыр сугыш чорына туры килә аның.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 4 абыйсы да яу кырына китә, әтисе трудовая армиягә алына. Тормыш авырлыгы әнисе белән Хәкимулла абый җилкәсенә төшә. 11 яшеннән ат белән тырмага, сукага чыга. Сугыш беткәч, атлы лобогрейкада эшли, тракторда плугарь булып йөри. Атлар карый.

1952-1994 нче елларда Түбән Шытсу авылы фермасында мөдир булып эшли. 1994 нче елда лаеклы ялга чыга. Эшләгән чорда бик күп **грамоталар**, **Рәхмәт хатлары** белән бүләкләнә. **“Почет Билгесе” ордены**на лаек була.

Хәкимулла абый Түбән Шытсу авылы кызы Мәгъмүрә апа белән тормыш кора. Алар 3 ул, 1 кыз тәрбияләп үстерәләр.

Бүгенге көндә Хәкимулла абый улы Илгиз һәм килене Алсу гаиләсе белән Түбән Шытсу авылында яши.

# Ханипова (Яруллина) Шәфига Таһир кызы



Ханипова Шәфига Таһир кызы 1943 нче елның 12 нче августында Түбән Шытсу авылында туа. Әтисе Таһир, сугышка киткәч, каты яраланып госпитальгә эләгә. Өйгә кайтып, тәмам терелгәч, кире сугышка дип чыгып китә. Ләкин ул кулына автомат тотып сугыша алмый. Аны сугышка җибәрмиләр. Ул Шәмәрдәндә торып тимер юл салуда эшли. Аннан урман кисүчеләрнең бригадиры була. Сугыш беткәч, авылга әйләнеп кайта. Ләкин бик нык авырый.

Шафига апа 1950-57 нче елларда мәктәптә укый. Мәктәптә укыган елларда кызлар белән комбайннан салам төшерергә йөриләр. Мәктәп бетергәч, фермага эшкә керә. Башта яшь бозаулар, аннан сарыклар карый. Соңыннан сыер саварга күчерәләр. Аның исеме Почет тактасында даими эленеп тора. Медаль белән бүләкләнә.

Авыру сәбәпле фермадан чыгып, мәктәп ашханәсенә эшкә керә Шәфига апа. Аның пешергән ризыкларын ул заман укучылары бүген дә мактап искә алалар.

Тормыш иптәше Рәүф абый белән 3 бала үстерәләр.

# Хасаншина (Нургалиева) Нурлыбанат Нургали кызы



Хасаншина Нурлыбанат Нургали кызы 1937 нче елның 11 нче гыйнварында Югары Шытсу авылында тулы гаиләдә дөньяга килә. Әтисе Нургали абый склад мөдире булып эшли, ә әнисе Маһибанат апа колхозда төрле эшләрдә эшли. Әтисе Нургали абый 1941 нче елда Бөек Ватан сугышына китеп, алты елдан соң гына әйләнеп кайта. Әтиләре сугышка киткәч, Нурлыбанат апа әнисенә йорт эшләрендә булыша. Ачлык, ялангычлык аларны да урап узмый.

Сугыш бетү хәбәрен ул урамнан ишетеп кερә. Әтисенең сугыштан кайтуы зур шатлык була. Сугыш бетте дигәч тә, тормыш тиз генә рәтләнеп китмәгән, чөнки илгә зур зыян килгән. Басудан черек бәрәңге җыеп кайтып ашаулары бүгенгедәй хәтерендә Нурлыбанат апаның.

Нурлыбанат апа 1960 нчы елда Түбән Шытсу авылы егете Шамил абыйга кияүгә чыга. Алар дүрт бала үстерәләр. 53 ел бергә яшиләр.

Нурлыбанат апа хезмәт юлын Түбән Шытсу мәктәбендә техник хезмәткәр булып башлый һәм шунннан лаеклы ялга чыга. Хезмәттәге уңышлары өчен **“Ветеран труда” медале** белән бүләкләнә.

Нурлыбанат апа бүгенге көндә Түбән Шытсу авылында гомер кичерә.

# Хафизова (Шарифуллина) Сәйдә Мәснәви кызы



Хафизова Сәйдә Мәснәви кызы 1938 нче елның 4 нче августында Башкортстан Республикасының Илеш районы Төбәк авылында туа. Сугыш башланганда аңа 3 яшь була. Сугыш башлануга әтиләре сугышка китә. Сугыш беткәч тә кайтмый, солдат хезмәтендә кала.

Сугыш чорындагы ачлык, ялангычлык аның тормышын да читләтеп үтми. Сәйдә апа 7 класс белем ала. Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында гомер итә.

# Хафизов Газизулла Хафиз улы



Хафизов Газизулла Хафиз улы 1938 нче елның 15 нче августында Югары Шытсу авылында туа. Сугыш башланганда аңа 3 яшь була. 1942 нче елда әтисен Сталинград сугышына алалар, ул шуннан әйләнеп кайтмый. 1941 нче елда аларның гаиләләре Читада була, 1944 нче елда әниләре белән кире авылга кайталар. Аларның өйләрендә эвакуацияләнгән урыс хатыннары тора.

Сугыш беткәнен авылга солдатлар кайта башлагач беләләр.

“Колхозда эшләдек. Авырлыклар күп булды, аларны хезмәт белән җиңәргә тырыштык. Ашарга булмады,черек бәрәңге,үлән ашадык” – дип искә ала Газизулла абый.

Хатыны Сәйдә апа белән бер кыз тәрбияләп үстерәләр алар, 2 оныклары бар. Бүгенге көндә Газизулла абый белән Сәйдә апа Югары Шытсу авылында гомер итәләр.

# Хуҗаҗанова (Сәмигуллина) Гыйльминур Хәлиулла кызы



Хуҗаҗанова (Сәмигуллина) Гыйльминур Хәлиулла кызы 1940 нчы елның 5 нче маенда Түбән Шытсу авылында туган. Әтисе - Хәлиулла, әнисе - Гыйззениса. Гаиләдә алар 7 бала була. Өч туганы яшьтән үлә.

Әтисе аерым хуҗалык булып торган. Колхозга кермәгәч, аларның гаиләләренә түләүне икеләтә салганнар. Алар аны түли алмаган. Шуның өчен аны төрмәгә утырткannar. Ул шунда үлә.

Әтисе кулга алынганда, Гыйльминур апага 2 яшь була. Аларның тормышлары бик авыр булды. Ул 8-9 яшьтә колхоз эшенә йөри башлый.

Гыйльминур апа 1949-56нчы елларда Түбән Шытсу җидееллык мәктәбендә белем ала. Мәктәпне бетергәч, колхозда төрле эштә, аннан соң фермада сыер сава, лаборант булып эшли.

1961 елда Түбән Шытсу авылы егете Мәүлетҗан абыйга кияүгә чыга. 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Анның 3 оныгы һәм 3 оныкчыгы бар.

1971 елда пекарняга ипи пешерүче булып эшкә керә. Анда 25 ел эшли.Пекарняда эшләгәндә колхоздагы төрле эшкә дә йөри. Кул эшенә дә оста була. Шәл, носки,бияләйләр бәйләп сата. Тегүгә дә оста була.

Гыйльминур апа 1995 елда лаеклы ялга чыга. Ул тырыш хезмәтләре өчен бик күп Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Бүгенге көндә Түбән Шытсу авылында яши.

# Хуҗин Рәхимҗан Гобәйдулла улы





Хуҗин Рәхимҗан Гобәйдулла улы Түбән Шытсу авылында 1941 нче елның 1 нче мартында туа. Әтисе - Хуҗин Гобәйдулла, ә әнисе - Хуҗина Бибигайшә. Түбән Шытсу авылында урта белемне алгач, институтка укырга керә Рәхимҗан абый, ләкин аны бетерә алмый. 14 яшендә шофер ярдәмчесе (плугар) булып эшли башлый, соңыннан төрле эштә ат белән йөри.

19 яшендә, 1960 нче елның 17 нче октябрендә, армиягә китә ул. Кастроманың военно-ракетный частендә 3 ел 2 ай хезмәт итә. Армиядән кайткач, өйләнә. Аның хатыны - Хуҗина Елизавета Васильевна. 1967нче елда Альберт исемле малае, 1971 нче елда Эльвира исемле кызы туа. Баштарак колхозда шофер булып эшли. Аннары 1976 нчы елларга хәтле мастерскойда хезмәт куя. Соңрак Васильево поселыгына китә, анда да шофер булып эшли. 2001 нче елда Тубән Шытсуга кайта һәм пенсиягә чыга, фермада каравылда эшләп ала.

Хәзерге көндә Түбән Шытсу авылында яши.

# Хөснуллина (Харисова) Фирая Харис кызы



Хөснуллина (Харисова) Фирая Харис кызы 1936 нчы елның 16 нчы ноябрендә дөньга килә.

Тик 1941 елда авылга килгән кайгы алар гаиләсен дә читләтеп үтмәгән. Фирая апага 4 яшь тә 8 ай булганда әтиләрен сугышка озата алар. 1942 нче елның 30 нчы декабрендә аларга кайгылы хат килеп төшә ( үзе әйтүенчә, “кара печатьле кәгазь”). Әтисе яу кырында һәлак була.

Фирая апа 1943 нче елның 1 нче сентябрендә Түбән Шытсу башлангыч мәктәбенә укырга керә. Җидееллык мәктәпне 1952 елда тәмамлап чыга ул.

Ашарга булмагач, кычыткан, ат кузгалагы, ак чәчәк җыеп, яз көне кар астыннан чыккан өшегән бәрәңге ашау хәтерендә нык уелып калган Фирая апаның.

Сугыш беткән дигән хәбәрне 1945 нче елның 9 нчы маенда мәктәп ишек алдында линейка тезеп зур шатлык белән җиткергәннәр аларга. Тик әтисе генә кире әйләнеп кайта алмаган шул...

1952-1954 нче елларда Фирая апа әнисе белән тавык фермасында, ә 1954-1962 нче елларда сөтчелек фермасында сыер савучы булып эшләгән. 1962 нче елда Хөснуллин Гасим Хөснулла улы белән гаилә корганнар һәм бер ул үстергәннәр. 1962 нче елдан 1991 нче елга чаклы шул фермада бозау караучы, сыер савучы булып эшләгән Фирая апа, 1991 нче елда лаеклы ялга чыккан.

Хәзерге көндә тормыш иптәше Гасим белән тигезлектә, уллары Васил һәм киленнәре Рушания тәрбиясендә бик бәхетле мул тормыш кичерәләр. Фирая апаның бүгенге көндә бер баласы, өч оныгы һәм өч оныкчыгы бар. Сугыш елларында күргәннәрен Фирая апа күз яше белән искә ала һәм киләчәк буынга андый афәтне күрсәтмәсен, дигән теләктә кала.

# Хөснуллин Гасим Хөснулла улы

Хөснуллин Гасим Хөснулла улы 1934 нче елның 28 нче октябрендә Түбән Шытсу авылында туа. 1941 нче елның 1 нче сентябрендә башлангыч мәктәпкә укырга керә.

"Бер көнне “большевик” кушаматлы, бригадир булып эшләүче Шигабиев Зиннур абый, ярсып чапкан атын туктатып: “Сугыш башланган”, - диде. Бу – халык өчен коточкыч хәбәр иде," - дип искә ала Гасыйм абый.

Җиңү хәбәрен китергән көнне дә бик яхшы хәтерли ул.

"1945 нче елның 9 нчы мае көнне безне, барлык укучыларны, мәктәп ишек алдына линейкага тезделәр һәм сугыш беткәнлеге хакында хәбәр иттеләр. Укытучылар безне җиңү көне белән котладылар," - дип сөйли Гасыйм абый.

1950 нче елда ул җидееллык мәктәпне тәмамлый.

1953-1956 нчы елларда Совет Армиясы сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, колхозда ферма мөдире булып берничә ел эшли. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, күпчелеге 1948-1949 нчы елгы яшьләр белән, 1967 нче елда кичке урта мәктәпне, 1968 нче елда читтән торып Минзәлә совхоз техникумын тәмамлый Гасыйм абый.

1957-1960 нчы елларда колхозда төрле эшләрдә, 1960-1964 нче елларда ферма модире, 1964-1968 нче елларда колхозда бухгалтер, 1969-1973 нче елларда зоотехник, 1973-1977 нче елларда Түбән Шытсу авыл советы председателе, 1977-1990 нчы елларда колхоз председателе урынбасары, партия оешмасы секретаре, 1991-1995 нче елларда колхоз рәисенең терлек азыгы хәзерләү буенча урынбасары булып эшли ул. 1995 нче елда лаеклы ялга чыгуына карамастан, 2001 нче елга кадәр ындыр бригадиры вазыйфаларын башкара Гасыйм абый.

1962 нче елда Харисова Фирая Харис кызы белән тормыш корып, бер ул үстерәләр алар. Хәзерге көндә тормыш иптәше белән тигезлектә улы Васил һәм килене Рушания гаиләсендә бәхетле картлык кичерә Гасыйм абый. Зур байлыгы – өч оныгы һәм өч оныкчыгы бар. Сугыш елларында куйган фидакарь хезмәтләре өчен СССРның Югары Президиум Советы указы белән **“За трудовую доблесть”медале** һәм **Ветеран Труда медале** белән бүләкләнә Гасыйм Хөснулла улы.

# Шәвәлиева (Мусина) Фәймә Габдри кызы





Шәвәлиева (Мусина) Фәймә Габдри кызы 1944 нче елның 5 нче августында дөньяга килә. Югары Шытсу авылында башлангыч мәктәптә 4 класс белем ала, 5-7 нче сыйныфларны Түбән Шытсу мәктәбендә укый. 10 класс белемне кичке мәктәпкә йөреп ала.

Әтисе- Габдри абый сугышта катнаша. Аннан яраланып кайта. Шуннан соң озак еллар колхоз белән җитәкчелек итә.

Фәймә апа 1959 нчы елда фермага эшкә килә. 1970 нче елда Югары Шытсу авылы егете Сәгыйть абыйга кияүгә чыга. 2 бала тәрбияләп үстерәләр.

1981-87 нче елларда балалар бакчасында эшли.

1987 нче елдан фермада эшли. 2008 нче елда лаеклы ялга чыга Фәймә апа.

Бүгенге көндә тормыш иптәше Сәгыйть абый бакый дөньяга күчкән. Фәймә апа олы улы Илгиз гаиләсе белән яши.

Тырыш хезмәте өчен бирелгән бүләкләре бик күп.

**“Свидетельство о занесении в Книгу почета”**

**«Ударник коммунистического труда»- 1960 г.**

**«За доблестный труд в ознаменование 100 –летия со дня рождения Владимира Ильича Ленина»-1970 г.**

**«Победитель социалистического соревнования 1979 года»**

**Почет грамотасы:**

**1979,1980 елларда фермада яхшы күрсәткечләре өчен бүләкләнә.**

**Диплом:**

**1986-87, 1987-88 нче елларда фермадагы яхшы күрсәткечләре өчен бүләкләнә.**

**1998 елда “Ветран труда” бирелә.**

## Шарипова (Сәйфетдинова) Нәсимә Гыйльметдин кызы



Шарипова (Сәйфетдинова) Нәсимә Гыйльметдин кызы 1939 нчы елның 22 нче октярендә Түбән Шытсу авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 7 класс белем ала.

“Сугыш башланганны әтидән ишеттем. Ул өйдә ут күренмәсен өчен тәрәзәләрне каплап йөрде. Мин бәләкәй идем. Әтинең сугышка киткәнендә хәтерләмим. Әнинең басудан кайтканын көтеп йоклап китә идем,” – дип сөйли Нәсимә апа.

1943 нче елда Нәсимә апаның әтисе исән-сау туган якларына әйләнеп кайта. “ Әти кайтып кергәч, безнең ничек шатланганны күрсәгез иде. Әтинең генә бер аягы юк иде. Соңыннан аңа агач аяк куйдылар. Ул авыл советында, амбарда эшләде,” – дип дәвам итә Нәсимә апа.

Ул 1963 нче елда Түбән Шытсу авылы егете Рәхимҗанга кияүгә чыга. Алты бала үстерәләр.

Нәсимә апа 1955 нче елда фермага эшкә керә. Лаеклы ялга чыкканчы шунда эшли.

“20 сыерны кул белән сава идек. Эш бик авыр булды. Балаларның да үскәнен күрә алмадык. Бик күп Рәхмәт хатларым, медальләрем, грамоталарым бар,” - дип искә алды Нәсимә апа.

Бүгенге көндә, тормыш иптәше, Рәхимҗан абый бакый дөньяга күчкән. Нәсимә апа Түбән Шытсу авылында гомер итә.

# Шарифуллина (Габдрахманова) Миңсәрия Файзрахман кызы





Шарифуллина (Габдрахманова) Миңсәрия Файзрахман кызы 1939 нчы елның 15 нче маенда Түбән Шытсу авылында крестьян гаиләсендә туа. 7 класс белем ала. Миңсәрия апага 2 яшь вакытта әтисе Файзрахман абзый сугышка китә һәм кире әйләнеп кайтмый.

“Сугыш беткәнгә карап тормыш бик тиз генә җиңеләймәде. Укырга йөргәндә китап-дәфтәрне яулыкка төйнәп йөри идек. Укып бетергәнче җәй көне яланаяк, ә кыш көне бабай ясап биргән чабатаны киеп йөрдем. Әнигә ияреп чүп утарга, төрле эшләргә йөрдем. 2 тапкыр урман кисәргә дә бардым. Аннан соң фермада бозаулар карадым. Аннары пекарняда эшләдем,” – дип сөйли Миңсәрия апа.

1959 нчы елда Югары Шытсу егете Шарифуллин Габдрафикка кияүгә чыгып, 5 малай тәрбияләп үстерәләр алар.

Озак еллар Югары Шытсуда кибетче булып эшли Миңсәрия апа. “Ветеран труда” медаленә лаек була.

Бүгенге көндә Югары Шытсу авылында 4 нче улы Илшат гаиләсе белән яши ул.

“Бүгенге көннән бик канәгать. Без күргәннәрне беркемгәдә күрергә язмасын,”- дип тәмамлады Миңсәрия апа үзенең әңгәмәсен.

# Шарифуллина (Хабибуллина) Рәйсә Хабибулла кызы




Шарифуллина (Хабибуллина) Рәйсә Хабибулла кызы 1935 нче елның 1 нче мартында Елыш авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. 7 класс белем ала.

Әтисе Хабибулла абый, үпкәсе авыру сәбәпле, сугышка бармый. Тик аңа карап тормышлары бер дә җиңел булмый аларның.

Сугыш елларында ашарга, ягарга утын булмый, салам ягып яшиләр. Ул вакыттагы барлык гаиләләр кебек, бик күп авырлыклар кичерәләр. Кычыткан, алабута, чыпчык кузгалагы, черек бәрәңге ашап туеналар.

Бик яшьтән фермага эшкә керә Рәйсә апа. Елыш авылы егете Мәгъсүм абыйга кияүгә чыга. Аның белән биш бала тәрбияләп үстерәләр.

“Җирдә тынычлык булсын, яшьләр тыңлаучан, әйбәт булсыннар,” - дип киңәш итә Рәйсә апа.

# Шигапова Кәүсәрия Ахунҗан кызы



Шигапова Кәүсәрия Ахунҗан кызы 1933 нче елның 15 нче июлендә Арча районы Ашытбаш авылында туа. Сугыш башлануы турындагы хәбәрне кемнән ишеткәнен Кәүсәрия апа әйтә алмый. Әтисе Ахунҗан абзыйны сугышка озатканны да төш шикелле итеп кенә хәтерли.

Алар әниләре белән 6 бала калалар. Барлык сугыш елы балалары кебек үк, Кәүсәрия апа да һәртөрле авыр эшләрне эшләргә туры килгән. Алар барлык хуҗалык эшләрендә дә, колхоз эшләрендә дә катнашып, эшләп үскәннәр. Ашарларына булмаган диярлек, ачлык булган. Кемнәрнең әтиләре, абыйлары исән булып кайткан, аларга ипи сыныгы булса да биргәннәр, ә Кәүсәрия апаларга анысы да эләкмәгән.

“Сугышта җиңүне кешеләр урамнарда җырлый-җырлый бәйрәм итүеннән белдек,” - дип сөйләде Кәүсәрия апа. Кызганычка каршы, әтиләре сугыштан өйләнеп кайтмаган.

Кусәрия апа 7 класс белем ала. 1950-55 нче елларда Казанда конфет җитештерү фабрикасында эшли.

1955 нче елда Елыш авылы егете Нәҗип абыйга кияүгә чыга ул. Аның белән 5 ул, 1 кыз үстерәләр.

Бүгенге көндә Кәүсәрия апа улы Каюм белән Елыш авылында яши.

# Якупова (Хабибуллина) Саимә Госман кызы





Якупова (Хабибуллина) Саимә Госман кызы 1940 нчы елның 3 нче мартында Елыш авылында гади колхозчы гаиләсендә бишенче бала булып туа. 1941 нче елда сугыш башлангач, әтиләре сугышка китә һәм хәбәрсез югала.

“Без биш бала идек, әниебез карап үстерде.Әниебез көне-төне басуда булды. Без дә әни янына тырма белән башак җыярга йөрдек.Ашарга ипи юк иде. Өшегән бәрәңге ашадык. Өскә-башка юк, абыйдан калган костюмны кия идем. Мәктәпкә яланаяк йөрдем. Язарга ручка юк, перо белән яза идек,” – дип искә ала Саимә апа.

Саимә апа җиде класс белем ала. Мәктәпне тәмамлагач, хат ташучы булып эшли. Соңрак фермага эшкә урнаша. Елыш авылы егете Якупов Рәшит абыйга кияүгә чыга. Аның белән дүрт бала үстерәләр. Рәшит абый гына 36 яшендә каты авырудан соң вафат була. Саймә апага тагын авыр вакытлар килә. Ул берүзе дүрт кечкенә баланы тәрбияләп үстерә. Колхозга төрле эшкә йөри, клубта җыештыручы булып эшли. Саймә апа эштән курыкмый . Өлкән яшьтәгеләргә булыша. Өйдә дә маллар асрый.

Саймә апа бүгенге көндә улы Илдар гаиләсе белән Елыш авылында яши.

“Моннан соң балаларга, оныкларга ул язмышларны күрергә язмасын. Илләр тыныч, күкләребез аяз, йөзләребез шат булсын,” - дип догалар укый Саймә апа.

# Яппарова (Кәлимуллина)   Галия  Кәлимулла  кызы



Яппарова (Кәлимуллина)   Галия   Кәримулла   кызы   1942 нче елның  1 нче мартында  Түбән Шытсу авылында гади колхозчы гаиләсендә 12 нче бала булып дөньяга килә. Әтисе, олы яшьтә булу сәбәпле, сугышка бармый.

Галия апа 7 класс белем ала. Укуын бетергәч, фермада сыер сава, сарыклар карый.


“Менә 1945 нче елда сугыш бетте, Аллага шөкер. Ләкин әле аның нужасы 60 нчы елларга кадәр дәвам итте. Җаннар әрни иде, өй тулы, ач, ялангач балалар. Әниләре аламаларына төренеп, 200 грамм солы кибәге өчен бер көн калмый эшләп йөриләр иде. Ә хезмәт хакын таяклап, сутыйлап язалар иде (бер тиенсезгә). Инде, Ходаем, безнең балаларыбыз, без күргәннәрне күрмәсеннәр иде. Оныкларыбыз яхшы мәктәпләрнең кадерен белеп, укытучыларын хөрмәт итеп яшәсеннәр иде. Аларга бәхетләр, тәүфыйклар телим,”- ди Галия апа.



1963 нче елда Түбән Шытсу авылы егете Яппаров Шафигулла абыйга кияүгә чыга ул. Аның белән 2 кыз, 1 ул үстерәләр.

Галия апа хат ташучы булып та эшли. Яхшы эшләгәне өчен бик күп **мактау хатлары** белән бүләкләнә.

Бүгенге көндә Галия апа малае Рәшит белән Түбән Шытсу авылында гомер кичерә.


| **Ф.И.О.** | **Туган елы** | **Туган урыны** | **Әтисе турында мәгълүмат** | **Эш урыны, бүләкләре** | **Үлгән елы** | **Күмелгән урыны** |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Алексеева Хәлимә Алексей кызы** | 20.12. 1936 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышка бармаган | “1-Май” колхозында сыер савучы була | 04.11. 2006 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Әдһәмова Гамбәр Билал кызы** | 07.02. 1934 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан | “1-Май” колхозында сыер савучы була | 08.08. 2015 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Әхмәтвәлиева Вәсилә Сәлимҗан кызы** | 23.06. 1934 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе турында мәгълүмат юк | “1-Май” колхозында терлекчелектә эшли | 03.01. 2011 | Саба районы Югары Шытсу авылы |
|  **Әхмәтова Фатыйма Сәгыйть кызы** | 05.04. 1936 | Саба районы Елыш авылы | Әтисе сугышка бармаган | Елыш авылы мед. пунктында санитарка була | 01.05. 2004 | Саба районы Елыш авылы |



| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Баһманова Нурия Баһман кызы** | 07.10. 1934 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 28.08. 2013 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Билалов Зөфәр Билал улы** | 05.09. 1933 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе турында мәгълүмат юк | Икшермә урта мәктәбендә , “1 Май” колхозында, шофер була | 26.12. 2015 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Вафин Тимергали Вафа улы** | 12.02. 1935 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә, пекарняда эшли | 29.01. 2003 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Галиәхмәтов Мөктәсим Галиәхмәт улы** | 02.01. 1933 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозы, фермада, умартачылыкта эшли | 13.06. 2012 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Галиәхмәтов Рафик Галиәхмәт улы** | 1935 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе турында мәгълүмат юк | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 1974 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Галиәхмәтова Зөһрә Баһман кызы** | 1938 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 29.05.1998 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Галиәхмәтова Шәргыя Галиәхмәт кызы** | 05.06.1940 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 14.06.2005 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Галиев Галим Мөхәмәдияр улы** | 28.09.1941 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | Казанда заводта эшли | 06.12.2010 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Гаптрахманов Рифкать Файзрахман улы** | 13.02.1942 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 08.11.2005 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Гарипов Фатыйх Кәнәфи улы** | 1948 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | Киномеханик булып эшләгән | 28.11.1975 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |


| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Гарипова Рәйсә Гаяз кызы** | 02.06. 1934 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | Түбән Шытсу авылында клуб мөдире, кибетче була | 03.04. 2007 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Гарифуллин Абдулла Гарифулла улы** | 18.05. 1938 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе турында мәгълүмат юк | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли. | 12.10. 2009 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Гәрәев Гәлиәхмәт Гәрәй улы** | 04.10. 1936 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак була | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли. **Медаль “За трудовую доблесть», Орден «Трудового Красного Знамени»** | 14.04. 2014 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Гәрәева Фәнүрә Салих кызы** | 08.07. 1936 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак була | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли. **Орден Трудовой Славы III степени** | 10.02. 2016 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Гыйбадуллин Хәбир Сибгатулла улы** | 04.01. 1940 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган. | “1 Май” колхозында көтүче була, соңрак фермада эшли | 23.06. 2003 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Гыйльманова Саймә Латыйп кызы** | 05.03. 1941 | Кукмара районы, Туембаш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 19.06. 2016 | Саба районы, Елыш авылы |
| **Гыймадиев Төхбатулла Гыймазетдин улы** | 09.12. 1937 | Саба районы Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 14.08. 1985 | Саба районы Югары Шытсу авылы |
| **Гыймадиев Имаметдин Гыймади улы** | 1934 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә, умартачылык та эшли | 06. 1973 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
| **Гыймадиева Нурия Гаян кызы** | 1940 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
| **Җиһаншин Гәбделбәр Гайсә улы** | 12.03. 1941 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | Шахтада эшли | 07.10. 2014 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
| **Җиһаншин Мансур Җиһанша улы** | 1939 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 16.07. 2001 | Саба районы, Елыш авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Зәкиҗанов Сабирҗан Зәкиҗан улы** | 21.10. 1938 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында тракторист булып эшли | 21.08. 2001 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Зәкиҗанова Зәйтүнә Сабур кызы** | 24.05. 1933 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе Суслан-гер лагерендә һәлак була | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 20.10. 2012 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Зәкиҗанова Фәния Зәкиҗан кызы** | 25.01. 1934 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | Казан шәһәрендә эшли | 20.11. 2011 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Зиннурова Нажия Зиннур кызы** | 25.02. 1932 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | Түбән Шытсу мәктәбендә укытучы, Елыш авылында клуб мөдире була | 22.01. 1998 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Ибиятуллин Рәшит Ибиятулла улы** | 10.10. 1939 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 7.12. 1967 | Саба районы, Елыш авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Ибраһимов Хәмит Салих улы** | 05.12. 1936 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында бригадир вазыйфасын үти | 20.07. 2011 | Саба районы, Елыш авылы |
| **Ибраһимова Нәзирә Сафуан кызы** | 20.05. 1932 | Теләче районы, Сос- Мысь авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | Казан шәһәрендә заводта эшли | 30.08. 2005 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Касыймов Сәмигулла Касыйм улы** | 27.01. 1935 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта булмаган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли. | 03.06. 2002 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Касыймова Гайния Солтан кызы** | 12.06. 1936 | Саба районы Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта була, бер аяксыз кайта. | “ 1 Май” колхозында фермада эшли. **”Ана даны” медаленә ия була.** | 12.02.2 010 | Саба районы Югары Шытсу авылы |
|  **Кәлимуллина Сәвия Хужи кызы** | 20.01. 1934 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 05.12. 2010 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Мәхмүтов Әмиржан Мәхмүт улы** | 25.05. 1937 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында тракторист булып эшли | 16.04. 2002 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Миннебаев Вәгыйз Сабиржан улы** | 07.04. 1933 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайта | “1 Май” колхозында тракторист булып эшли | 05.09. 1993 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Миннебаев Гомәр Хабибулла улы** | 10.02. 1938 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайта | “1 Май” колхозында тегермәнче булып эшли | 20.12. 2013 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Миннебаева Зәкия Хәсән кызы** | 10.11. 1937 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 13.03. 2001 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Мифтахова Миңленур Арслан кызы** | 16.05. 1940 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугыштан бер аяксыз кайта | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 14.05. 2015 | Саба районы, Елыш авылы |


| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Мөбәрәкшин Шәймөхәммәт Мөбәрәкша улы** | 21.10. 1939 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта булмаган | “1 Май” колхозында бухгалтер булып эшли | 18.06. 2011 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Мусин Малик Габдрахман улы** | 11.11. 1936 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан бер кулсыз кайта | “1Май” колхозында механик булып эшли | 25.10. 2008 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Мусин Рифкать Мөхәммәтша улы** | 25.07. 1942 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайта | “1 Май” колхозында механизатор, слесарь булып эшли | 18.03. 2001 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Мусина Рәзифә Рамазан кызы** | 13.10. 1939 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайта | “1Май” колхозында дунгызчылык та эшли | 18.03. 1984 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Нәбиуллин Әглиулла Хидиятулла улы** | 09.01. 1935 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайта. | “1 Май” колхозында бригадир булып эшли. | 14.01. 2007 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Нәбиуллин Рифнур Әхтәм улы** | 15.03. 1939 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 18.10. 2007 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Низамиев Миннәхмәт Низами улы** | 10.04. 1934 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта булмаган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 29.03. 2013 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Низамиева Хәтирә Гәбделхак кызы** | 16.02. 1938 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1Май” колхозында төрле эштә эшли | 16.07. 2002 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Нотфуллин Индус Төхбәтулла улы** | 15.05. 1939 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли | 01.03. 1991 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Нуриәхмәтов Сәүгән Нуриәхмәт улы** | 01.04. 1938 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1Май” колхозында мастерской мөдире булып эшли | 27.05. 2009 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Нуриәхмәтова Васимә Әхтәмҗан кызы** | 03.06. 1939 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында сыер савучы булып эшли | 29.01. 1990 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Рамазанов Зәкиҗан Идиятулла улы** | 29.11. 1941 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли. “Победитель социалистического соревнования 1975 года” значогы белән бүләкләнә | 29.04. 2010 | Саба районы, Елыш авылы |
| **Рәхиева Нурзидә Гобәйдулла кызы** | 11.04. 1941 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында сыер савучы булып эшли. | 12.05. 2004 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Сабиров Рәшит Мәннән улы** | 1935 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | Кукмарада мәдәният йортында эшли. Кукмара халык театры артисты | 13.01. 2011 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Сабиров Рифкать Мәннән улы** | 30.09. 1938 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли | 04. 2003 | Саба районы, Елыш авылы |


| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Салихов Хатыйп Салих улы** | 19.07. 1934 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе турында мәгълүмат юк | “1 Май” колхозында терлекчелек тә эшли | 23.05. 1972 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Салихова Минзифа Фазлый кызы** | 19.04. 1935 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 21.03. 2004 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
| **Салихова Сабира Галимулла кызы** | 20.05. 1933 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта булмаган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 17.11.2 016 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Сафиуллин Сафуан Файзрахман улы** | 21.05. 1934 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында шофер булып эшли. | 28.10. 2005 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Сафиуллина Гәдәния Ибраһим кызы** | 06.08. 1934 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 12.09. 2010 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Сәлмәнов Ләбиб Нури улы** | 21.02. 1938 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 29.01. 2013 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Сәлмәнова Нурия Миннехан кызы** | 01.03. 1940 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1Май” колхозында төрле эштә эшли. | 20.09. 1982 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Сөнгатуллин Тимершәех Сөнгатулла улы** | 31.01. 1938 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли | 08.04. 2012 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Тимербаева Әлфинур Зәкиржан кызы** | 1935 | Теләче районы, Урта Мишә авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 17.11. 2001 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Усманов Нияз Госман улы** | 1932 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли | 27.08. 2007 | Саба районы, Елыш авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Усманова Рәйсә Вәли кызы** | 19.03. 1941 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 06.05. 2004 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Фәйзрахманов Мәгъсүм Файзрахман улы** | 09.06. 1936 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан яраланып кайта. | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли. **Ул бик оста көрәшче була.** | 18.11. 1999 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Фәйзрахманова Тәскирә Зиннур кызы** | 11.09. 1941 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1Май” колхозында терлекчелектә эшли. | 10.06. 2004 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
| **Фәләхиева Зәйнәпбикә Шәмсе-мөхәммәт кызы** | 24.08. 1937 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 20.10. 1996 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Хабибрахманов Фәткрахман Хабибрахман улы** | 02.06. 1944 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында прораб, завхоз булып эшли. **“Двадцать лет Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.” медаленә ия** | 12.05. 2014 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Хабибуллина Халисә Рәшит кызы** | 21.01. 1942 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 01.06. 2013 | Саба районы, Елыш авылы |
| **Харисов Хатип Харис улы** | 24.08. 1934 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 07.08. 2002 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
| **Харисова Сылубикә Вәлиулла кызы** | 24.04. 1940 | Теләче районы, Алан-Җөри авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында сыер савучы булып эшли | 22.05. 2005 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Хафизов Хамидулла Хафиз улы** | 03.01. 1935 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе Сталин-град сугышын-да һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли. | 15.04. 2016 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Хафизова Миңсәрия Нотфулла кызы** | 13.08. 1937 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли | 21.03. 1992 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Хәнипов Рәуф Җәләлетдин улы** | 06.08. 1938 | Саба районы Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли | 05.10. 1998 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Хәсәншин Шамил Хәсәнша улы** | 23.08. 1934 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | Түбән Шытсу мәктәбендә завхоз булып эшли | 09.11. 2014 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Хөснуллин Мөктәсим Хөснулла улы** | 22.02. 1937 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында терлекчелектә эшли. “Татарстанның атказанган терлекчесе” исеменә лаек була. | 02.09. 2015 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Хөснуллина Рәшидә Кадыйр кызы** | 01.06. 1941 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында сыер савучы булып эшли | 29.06. 2000 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Хуҗаҗанов Мәүлетҗан Хуҗаҗан улы** | 18.04. 1933 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында электрик булып эшли | 19.06. 1992 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Шакиров Заһретдин Шакир улы** | 17.09. 1935 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында экономист булып эшли | 09.02. 1996 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Шакирова Нәсимә Галим кызы** | 1940 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | Түбән Шытсу авылында пекарняда эшли | 1984 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Шәвәлиев Сәгыйт Габделвәли улы** | 29.04. 1939 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли | 18.02. 2011 | Саба районы Югары, Шытсу авылы |
| **Шәвалиев Сәлихҗан Габделвәли улы** | 1938 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында механизатор булып эшли | | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Шәйхиева Рәйсә Нәҗәр кызы** | 05.01. 1935 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли. | 29.05. 2007 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Шәрифуллин Габдерафыйк Шәрифулла улы** | 7.03. 1934 | Саба районы, Югары Шытсу авылы | Әтисе сугышка бармаган | Түбән Шытсу авылында клуб мөдире, страховой агент, умартачы | 15.06. 1999 | Саба районы, Югары Шытсу авылы |
|  **Шиһабиев Равил Харис улы** | 25.10. 1939 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында механизатор, шофер булып эшли | 11.06. 2011 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Якупов Гаделхай Хәмит улы** | 15.06. 1940 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе Фин сугышын-да һәлак булган | Клуб мөдире, “1 Май” колхозында тимерче булып эшләгән | 18.05. 2000 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |
|  **Якупов Рәшит Сабирҗан улы** | 08.07. 1938 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 21.04. 1974 | Саба районы, Елыш авылы |
|  **Якупова Әминә Әскәр кызы** | 13.09. 1935 | Саба районы, Елыш авылы | Әтисе сугыштан исән-сау кайткан | Елыш авылында сөт җыя, клуб мөдире булып эшли. | 13.03. 1999 | Саба районы, Елыш авылы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
|  **Яппаров Шәфигулла Фәрхулла улы** | 08.11. 1938 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы | Әтисе сугышта һәлак булган | “1 Май” колхозында төрле эштә эшли | 04.09. 2002 | Саба районы, Түбән Шытсу авылы |

***Альбомны
Түбән Шытсу төп мәктәбе
коллективы башкарды
2017 ел***